А. Г. ЯХИН

Әдәбият

2

Беренче кисәк

«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

Әдәбият
А. Г. ЯХИН
2

А. Г. Яхин

Әдәбият

Дүртьеллык башлангыч татар мәктәбенең
2 нче сыйныфы өчен дәреслек

Ике кисәктә

БЕРЕНЧЕ КИСӘК

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан рөхсәт ителгән

КАЗАН • «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ • 2009

УДК 373.167.1:821.512.145*02
ББК 84(2Рос=Тат) я71
Я89

Рәссамнары:
Рәисә Сәйфуллина, Алексей Мамаев

Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Шартлы билгеләр:

?! — сораулар һәм биремнәр;

— иҗади эш.

Яхин А. Г.

Я89 Әдәбият : Дүртьеллык башл. татар мәкт. 2 нче с-фы өчен д-лек : Ике кисәктә. Беренче кисәк / А. Г. Яхин.— Казан : Мәгариф, 2009.— 159 б.
ISBN 978-5-7761-1954-5

ISBN 978-5-7761-1954-5

© «Мәгариф» нәшрияты, 2009
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2009

Әсәрдәге могҗиза.

Могҗиза — искитәрлек нәрсә ул. Аны күрә белергә генә кирәк. Ә күрә белсәң, сокланып туя алмыйсың. Могҗиза — сер ул. Аны хәтта серен белмәсәң дә яратасың. Ә серен белсәң, күбрәк тә ярата башлыйсың.

Могҗиза бит ул адым саен. Аны күреп соклана белүчеләр генә сирәк. Андыйлар бәхетле кешеләрдер, мөгаен. Могҗизалар дөньясына безне, әлбәттә, әкиятләр алып керә. Анда борын-борын заманда яшәгән әбиләр, карт булсалар да, чаптар атларны узып чабалар, җиргә көзге ташлап, диңгез ясыйлар. Айга кунакка менеп төшү дә берни тормый: себеркегә атлан да оч кына. Ә инде дуслар кирәк булса, бер сукмактан бар да бар. Кем генә очрамас сиңа. Дусларыгыз күбәер дә күбәер... Күр әле! Могҗиза ул дусларың күп булу икән дип, үзегез өчен ачыш ясарсыз. Дусларны эзләп, әллә кайларга барасы да юк. Алар хәтта әкиятләрдә дә күп икән дип сөенерсез.

Могҗиза турында бер балалар язучысы менә ничек язган.

«Минем кечкенә укучым!

Сезнең өчен әкият язарга утыру белән, бала чагымның алтын өе исемә төшә. Шул чакта мин үземне әлеге алтын өйгә әйләнеп кайткандай хис итәм. Ул өйдә мин сезнең белән очрашам. Сезнең янда үземнең бабамны, әбиемне күреп шатланам. Мич артындагы чикерткә җырлавын ишетеп сөенәм... Без барыбыз да шау-гөр килеп сөйләшәбез, көлешәбез, әкиятләр сөйлибез. Алтын өемне искә төшергәндә, шатлыгым эчемә сыймый.

Их, мин язган әсәрләр сиңа да шатлык китерсә иде! Мин кичергән шатлыкның бер генә өлеше сиңа да күчсә иде! Ул чакта минем шатлыгым тагын да артыр, бу дөньяда миннән дә бәхетле кеше булмас иде...

Син миннән кайчак: «Кайда соң ул бабайлар сөйләгән алтын өй?» — дип сорыйсың. Уйлап кара әле. Әбиең, минем әбием, гомумән, әкият сөйләргә яратучы башка кешеләр сөйләгән ул өйне син үзең дә бик яхшы беләсең бит. Көмеш идәнле, шикәр тәрәзәле, прәннек түбәле алтын өйне белмисеңме? Исеңә төшер әле. Анда кояш үзенең җиде төсе белән ялтырап елмая. Төрле-төрле кошчыклар ярыша-ярыша сайрыйлар. Әллә синең яктылык, бәхет, шатлык патшалыгын күргәнең юкмы?

Укудан, уеннан арып кайткач, әниеңнең, әбиеңнең яки бабаңның тезенә башыңны куеп, төш күргәндә, әллә син прәннек түбәле, көмеш идәнле алтын өйдә яшәмисеңме?

Акыллы сүзләр сөйләүче, калын-калын китаплар укучы, эшләпә киеп йөрүчеләр — без дә кайчандыр ул өйдә яшәдек. Без ул алтын өйне сезгә калдырып киттек. Хәзер без аңа беркайчан да әйләнеп кайта алмабыз. Эченә тынычлык, бәхет, шатлык тулган алтын өй турында әкиятләр сөйләрбез. Ә сез беләсезме ул могҗизаның исемен? Ул могҗизаның исеме — **Балачак**».

Әкиятләр укып, могҗиза дөньясын гизү — үзе бер бәхет ул. Ләкин әдәби әсәрләрнең дә үз могҗизасы бар.

Габдулла Тукай — һәркайсыбызга таныш шагыйрь. Ул балалар өчен берсеннән-берсе матуррак шигырьләр иҗат иткән. Әдип шулай ук балалар өчен дәреслек тә язган. Бу дәреслек «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дип атала.

Габдулла Тукай китапның кереш өлешендә язучыларны бакчачылар дип атый. Бакчачылар сизгер күңелләрендә нәфис гөлләр үстерәләр. Мин шул гөлләрнең чәчәкләрен берәм-берәм җыеп алдым һәм сезгә тәкъдим итәм. Әйдә, балаларыбызның күзе гүзәл нәрсәләр күрергә ияләшсен, дип язган. Аннан соң чәчәкләр кебек матур әсәрләрнең тәэсире турында: «Кечкенәдән гүзәл әсәрләр укыган балаларның күңелләре дә, нечкә һәм гүзәл булып, шундый гүзәл вә изге нәрсәләрне генә сөючән булыр»,— дигән.

Күрдегезме? Бөек шагыйребез әдәби әсәрләрне дә могҗиза бакчасы белән тиңләгән.

Әсәр төзелешен өйрәнәбез.

Әйдәгез, бергәләп искә төшерик. 1 нче сыйныфта без әсәрдә катнашучылар белән таныштык. Алар арасыннан авторны табарга өйрәнә башладык.

Авторны табу бер дә кыен түгел икән. Әсәрне укып чыкканчы ук беләсең, андагы кош-кортлар безнеңчә сөйләшә башладымы — әһә, тавыкның кешечә сөйләшеп йөргәнен кемнең күргәне бар, кәҗәнең рәхмәт әйтүен кайчан ишеткәнең бар? Автор сөйләттерә аларны, дисең.

Авторны табуы җиңел дә түгел. Ничек җиңел булсын, әсәрдә күренми бит ул. Үзе бар, шул ук вакытта үзе юк та. Күп вакыт без аны үзебез белән сөйләшкәндә генә күргән кебек булабыз. Ул безгә сораулар бирә, эзләп табыгыз әле балалар, ди.

Нишләмәк кирәк, эзлибез. Эзли-эзли әсәр эченә килеп керүебезне сизми дә калабыз. Димәк, без дә, автор кебек, әсәрдә үзебез бар, үзебез юк. Менә шундый әкәмәт. Әсәр уку ул, качышлы уйнаган кебек, әсәр эчендә үзеңне үзең эзләү дә икән.

Ә иң мөһиме, узган уку елында без әнә шул дәшми генә сораулар бирүче авторны күрергә өйрәндек. Искә төшерик.

БАЛА БЕЛӘН КҮБӘЛӘК.

Б а л а:

Әйт әле, Күбәләк,
Сөйләшик бергәләп:
Бу кадәр күп очып,
Армыйсың син ничек?

Ничек соң тормышың?
Ничек көн күрмешең?
Сөйләп бирче тезеп,
Табаламсың ризык?

К ү б ә л ә к:

Мин торам кырларда,
Болында, урманда;
Уйныймын, очамын,
Якты көн булганда.

Иркәли һәм сөя
Кояшның яктысы;
Аш буладыр миңа
Чәчәкләр хуш исе.

Тик гомерем бик кыска:
Бары бер көн генә,—
Бул яхшы, рәнҗетмә
Һәм тимә син миңа!

Габдулла Тукай.

Шигырьдә бала күбәләкне күргән дә хәлен сорашкан. Автор бала турында шуннан башка берни әйтмәгән кебек. Ләкин без баланың үзеннән күпкә көчсез күбәләк белән үз итеп сөйләшүен күреп торабыз. Автор әйтмәсә дә күрсәтә бит.

Бала күбәләктән: «Күп очасың, армыйсыңмы? Тамагыңны туйдыра аласыңмы?» — дип сораша. Баланың автор безгә табарга кушкан тагын бер бик матур сыйфатын таптык. Ул ярдәмгә мохтаҗларны кызгана белә икән. Кызгана белү — кешеләрнең иң матур сыйфаты.

Бала, кеп-кечкенә булса да, күбәләкне яратып, ягымлы итеп сораулар бирә. Бу бала бигрәк шәфкатьле икән, дип тагын бер сыйфатын күреп алабыз. Бәя биреп кенә калсак, бер хәл әле, без ул баланы ярата да башладык инде.

Күбәләккә бәя бирик.

Күбәләк очып китми, балага ышана. Аңа үз итеп, шатлана-шатлана сөйли.

Без, укучылар, бәхетле күбәләкне дә яратырга өлгердек.

Ә автор безгә күбәләк бәхете турында берни дә әйтмәгән. Без күбәләк бәхетенә шатландык. Шул

ук вакытта аны кызгандык та. Аның бәхете нибары бер генә күлмәк бит.

Шигырьдәге могҗиза шуннан гыйбарәт. Аны эзләп табарга кирәк. Шигырь,— димәк, автор да, без дә катнашкан башка бер серле дөнья икән.

ЭШ.

Тынма, эшлә, и сабый! Бел, Тәңредән
эшләргә көн;
Эшләп аргачтан бирелгәндер тыныч
йокларга төн.

Иртә торгач та язарга, дәресең укырга тотын;
Тынма, эшлә, торма тик, тынсаң тынарсың
җомга көн.

Күр, ничек эшли кояш: иртә тора, таң аттыра,
Көнозын күктә йөзә һәм көн буена яктыра.

Соңра, арган төсле, ул ирнеп кенә тауга бата,
Йоклый рәхәт, ял итә һәм җир йөзен дә йоклата.

Син кояштан үрнәк алсаң, тырышлык итсәң һаман,
Күп арасында кояш күк ялтырарсың берзаман!

Габдулла Тукай.

?! **1.** Катнашучыларны әйтсәгез, шигырьнең ике өлешен табасыз.

2. Шигырьне ике өлешкә бүлегез һәм өлешләрнең икесенә дә исем бирегез.

3. Кояш сыйфатларын санап чыгыгыз.

4. «Кеше кояшка кайсы яклары белән охшарга тиеш?» — ди автор?

5. Шигырьдән авторны табыгыз.

БӘРЕЛДЕ.

Таеп егылгач,
Шәвәли бераз
Мактанып ятты:
— Зу-уп-зур Җир шары
Бә-әрелде миңа
Шу-ундый да каты!!

Шәукәт Галиев.

?! **1.** Шигырьнең ике өлешен әйтегез.

2. Шәвәли мактанчыкмы?

ТЫРЫШЫП УКЫЙСЫМ КИЛӘ.

Мин иптәшне ашыктырам,
Ул мине ашыктыра:
Мәктәп көтә,
Ерактан
Ул безне дәшеп тора.
Мәктәп эче җыйналган,
Матурланган, буялган.
Тезелеп тора парталар,
«Утыр»,— дип чакыралар.

Без дә бүген мәктәпкә
Буш кул белән килмәдек,
Һәрберебез җәй көне
Бер нәрсә хәзерләдек.
Рөстәм сөйли:
— Әти белән
Без утырттык агачлар, ди;
Хәзер безгә кунак булып
Килерләр сандугачлар, ди.

Берсе турист булып гизгән
Күлләрен, таулыкларын.
Ул эзләгән һәм өйрәнгән
Табигать байлыкларын...

Берсе сөйли:
— Мин урманда
Бик күп җиләк ашадым, ди.
Икенчесе:
— Җиләк нәрсә!
Мин планёр ясадым, ди.

Шылтырады кыңгырау,
Утырыштык тиз генә,
Апа чыкты...
Хәзергә
Шунда туктыйсы килә.
Шунда туктыйсым килә дә
Тырышып укыйсым килә.

Әхмәт Фәйзи.

?! **1.** Шигырьдә, авторны санамаганда, катнашучылар икәү. Нигә икәү генә, күбәү түгел?

2. Катнашучыларның хәрәкәтен белү өчен, «ул нишли?» дип сорау бирергә кирәк.

Катнашучыларның берсе — укытучы. Ул нишли? Икенче катнашучы нишли?

3. Әсәрне ике өлешкә бүлик. Беренче өлеш мәктәп турында. Икенчесен әйтегез.

4. Җәйге каникулыгызны сез ничек үткәрдегез?

КУРАЙЧЫ.

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер бай. Аның Гәрәй исемле улы булган, ди. Гәрәй, яшьтән үк атасының ялчыларына ияреп, ауга йөрергә яраткан. Ул вакытта урманнарда ерткыч хайваннар бик күп булган, ди. Беркөнне Гәрәй атасына:

— Атай, мин бүген ауга үзем генә барам,— дигән.

Атасы аңа ялгызына ауга барырга рөхсәт итмәгән. Гәрәй атасының сүзен колагына да элмәгән. Егетлеген күрсәтергә теләп, берәүгә дә әйтмичә, япа-ялгызы чыккан да киткән. Шул китүеннән кире әйләнеп кайтмаган. Бер көн үткән, ике көн...— Гәрәй һаман юк, ди. Бай ялчылары Гәрәйне көн эзләгәннәр, төн эзләгәннәр. Эзли торгач, атна да узып киткән. Гәрәй табылмаган.

?! Әкиятнең укылган өлешен кып-кыска итеп сөйләгез.

Бай ялчыларын җыйган да:

— Гәрәйне теләсәгез кайдан эзләп табыгыз. Кем дә кем, миңа кайгылы хәбәр алып кайтып, авызын ача, үзенә үпкәләсен. Ерткыч бүреләргә ыргытачакмын,— дигән.

Эзлиләр, и эзлиләр: Гәрәй юк та юк, ди. Урман, тауны бетереп эзли торгач, ертылып беткән канлы өс киемнәрен генә тапканнар. Авыр хәбәрне баланың әтисенә ничек әйтергә? Дөресен әйтер идең — башны бетерә. Юлда бер узгынчы карт очраган. Ялчылар картка хәсрәтләрен сөйләп биргәннәр. Киңәш сораганнар.

— Ярар, оланнар, хәзер йокларга ятыгыз, иртән юлга чыгарбыз, мин дә сезнең белән барырмын,— дигән.

Ялчылар тынычланып йокларга ятканнар, ди. Иртән күмәкләшеп юлга чыкканнар. Бай йортына кайтып җитсәләр, хуҗа аларны капка төбендә үк көтеп тора икән.

?! Әкиятнең укылган ике өлешен кушып сөйләгез.

— Йә, таптыгызмы? Нинди хәбәр китердегез? — дип сорый башлады, ди, бай ялчылардан.

Ялчылар бер сүз дә әйтмиләр, ди. Шулчак әлеге узгынчы карт кыныннан[1] курай тартып чыгарган да уйнап җибәргән.

---

[1] Кын — кылыч, хәнҗәр кебек кораллар өчен савыт, футляр.

Курайның тавышы шундый моңлы, сагышлы, ди, бакчадагы сандугачлар да хәйран калып, сайрауларыннан туктап тыңлап торганнар, ди.

Бай да, ялчылар да бер курайчыга, бер курайга карап торганнар да елап җибәргәннәр, ди. Бай курай моңыннан улының һәлак булуын аңлаган. Курай моңыннан ләззәт табып, кайгысын баскан, ди.

Менә шулай курайчы үз кураеның моңы белән кешеләрне үлемнән алып калган, кайгылының кайгысын баскан, ди.

?! Әкияттәге өч өлешне (өч вакыйганы) кушып сөйләгез.

КУРАЙ.

...Бик борынгы заманда безнең җирләрдәге бер хан үсмер малайларны берәм-берәм чакыртып, шулардан чәчен кырдыра торган булган. Әмма чәч кырган малайларның берсен дә хан кире кайтарып җибәрмәгән — һәркайсын шунда ук үтертә икән. Шулай итеп, ханның чәчен кырган күп кенә малайлар һәлак булганнар. Ни өчен хан аларны үтерткән? Моның сәбәбен берәү дә белмәгән. Менә көннәрдән бер көнне бер ялгыз хатынның бердәнбер малаена да чират җиткән: хан чәчен кырдырырга аны да чакырткан.

Малай хан сараена китәр алдыннан, әнисе аңа төче икмәк пешереп биргән: «Мә, улым, тамагың ачкач, утырып ашарсың»,— дигән.

Малай, төче икмәкне кыстырып, сарайга киткән, хан янына барып кергән һәм, күп сөйләшеп тормастан, ханның башын бик әйбәт юешләп, үткен пәке белән чәчен кыркып төшергән. Менә шул чакта ул гаҗәеп бернәрсә күргән: ханның башында имән бармак чаклы мөгезе бар, имеш!.. Хан шүрәле сыман мөгезле, имеш!..

Малай эшен бетергәч, хан аңа: «Син инде минем мөгезне күрдең, ханның мөгезе бар икән дип сөйләп йөрерсең, шуңа күрә мин сине үтертәм»,— дигән. «Ярый,— дигән малай, бер дә каушап тормыйча,— тик син миңа шушы икмәгемне генә ашап алырга рөхсәт итче». Хан рөхсәт иткән. Малай төче икмәген ипләп кенә ашарга тотынган. Ул, ашыкмыйча, авызын чәпелдәткәләп, бик тә тәмле итеп ашый икән. Хан да моның ашаганын карап тора торгач кызыгып киткән: «Икмәгең бик тәмле күренә, кая, миңа да әзрәк сындырып бир әле»,— дигән. Малай чамалап кына сындырып биргән. Хан ашый башлаган һәм, исе китеп, малайдан: «Нигә бу икмәк шулхәтле тәмле?» — дип сораган. Малай: «Әнием аны үзенең күкрәк сөтенә изеп пешерде шул!» — дип җавап биргән. Моны ишеткәч, хан шактый аптырап калган: «Алайса, без синең белән бер ананың сөтен капкан булып чыктык, без хәзер бертуганнар булабыз бит»,— дигән. Малай дәшмәгән. Ә хан, уйланып: «Бертуганны үтерергә ярамый бит әле, менә хикмәт нәрсәдә! — ди икән.— Ләкин үтертмичә дә булмый, чөнки син

минем мөгезне күрдең, халыкка сөйләп йөрерсең... Инде нишләтергә сине?..»

Малай бу юлы да дәшмәгән. Шуннан соң хан, бераз икеләнеп торгач, малайга: «Ярар, мин сине үтертмим,— дигән.— Ләкин бер шартым бар. Кырда кура дигән бер көпшә үсә, син аның кипкәнен чокыр башыннан табарсың. Менә шул көпшәне кисеп ал да, минем мөгез турында сөйлисең килгән саен, шуңа гына өрә торган бул... Аңладыңмы?.. Мөгез турында — ләм-мим!.. Телең кычыта башлады исә, көпшәне генә сызгыртырга тотын!.. Килештекме?»

Малай: «Ярый, риза»,— дигән, шуннан хан аны өенә кайтарып җибәргән.

Малайның вакыт-вакыт мөгез турында бик сөйлисе килеп китсә дә, вәгъдәсен бозмаган. Сөйлисе килгән саен, әлеге шул кырдан кисеп алган көпшәсен «гү-гү» өрергә тотына икән. Тора-бара ул көпшәнең түбән очына тишекләр дә ясаган. Тишекләргә баскалап, көпшәдән нечкә-калын тавышлар да чыгара башлаган. Шулай итеп, малай төрле көйләр уйнарга өйрәнеп киткән. Хәзер инде ул ханның мөгезе турында сөйлисе килгәндә генә түгел, ә телдән әйтә алмаган берәр уе, хәсрәте бар чакта да көпшәсен алып уйный икән. Искиткеч моңлы, матур уйнаган ул, кешеләр аны таң калып тыңлаганнар. Кеше әйтеп бирүдән гаҗиз хисләрне кузгатучы *курай* дигән гаҗәеп нәрсә әнә шулай туган.

Әмирхан Еники.

?! Хикәя курай турында. Ни өчен патша, малай яисә малайның әнисе турында түгел?

Җавап. Беренчедән, автор хикәясенә «Курай» дип исем биргән. Башкача әйтсәк, автор: «Мин курай турында яздым»,— дигән. Шулай булгач, курай турында сөйлик.

Хикәя болай бүленә: беренче өлештә курай тавышында мәгънә юк әле, мөгез сере генә бар. Шуңа күрә бу өлешкә «Мөгез сере» дип, ә хикәянең икенче өлешенә «Хисләр сере» дип исем бирәбез. Егет остарган саен, әйтеп булмый торган сер бик бай эчтәлек ала. Хәзер ул әйтеп булмый торган егет хисләрен, уйларын көй итеп уйный башлый.

Курайчы үз хисләрен көйгә салып уйный, ә без, тыңлаучылар, ул көйдәге сагышны үзебезнеке итеп кичерәбез. Җитмәсә, аңа үзебезнекен дә өстибез. Тел әйтә алмаган уйлар, сагышлар безнең күңелебездә дә тулып ята бит.

Курай әнә шундый көчкә ия. Шуңа күрә хикәянең төп катнашучысы булган.

КИТАП ДОКТОРЫ.

Әбиләр дә авырый,
Бәбиләр дә авырый...
Салкын тисә аз гына,
Дару кирәк барсына.
Чирли хәтта китап та.

Ник көләсең?.. Чынлап та,
Бите төшә, ертыла —
Ул бит көн дә тотыла.
Алам шуңа сак кына.

Авырдымы чак кына,
Чирен шундук күрәм мин,
Дәвасын да беләм мин.
Төбе төшсә төплим мин...
Әйткәнне һич көтмим мин.
Китапларың чирләсә,
Үз кулыңнан килмәсә,
Миңа китер туп-туры —
Мин аларның докторы.

Хәкимҗан Халиков.

?! **1.** Төп герой үзен «доктор» ди. Докторлар ничек дәвалыйлар? Башта: «Кай җирең авырта?» — дип сорыйлар. Аннан соң ни эшлиләр?

2. Китап докторы да, башта: «Кай җирең авырта?» — дип, китаптан сораша. Китап нәрсә дип җавап бирә?

3. Әйдәгез, шигырьне үзебез дәвам итик. Әсәргә тагын бер катнашучы кертик. Аңа Галия дип исем кушыйк. Галия дә китапларын дәвалый белә. Ләкин дәваламый. Шуңа да карамастан китап аларның икесен дә мактый. Ни өчен шулай итә: Галия аны дәваламый бит.

КЕСӘ.

Әйтегез, кесәмдә ник
Йөри бик дәү подшипник
Һәм бәләкәй подшипник,
Һәм болтларның төрлесе,
Ачкычы, өтергесе,
Җиз һәм бакыр алкалар,
Шөрепләр һәм гайкалар,
Һәм төрле тимерчыбык,
Һәртөрле тимер чыбык;
Кесәдән тора чыгып
Төрле тимер кисәге —
Юк аларның исәбе!
Ә???
Чөнки мин ни кисәм дә,
Трактор бөтен килеш
Сыялмый бит кесәмә.

Роберт Миңнуллин.

?! **1.** Бу уңган егетнең кесәсе сай — трактор да сыйдыра алмый. Аның кесәсе сай булуына кем гаепле: әнисеме, кием тегүчеме?

2. Шигырь өлешләрен табыйк. Беренче өлеш — булсынга йөрүче малай. Икенче өлеш — бар булганны юкка чыгаручы малай.

3. Ни өчен малай булсынга йөрүче? Ни өчен булганны әрәм итүче?

МАЯК.

Маяк армый, маяк талмый:
Көн буена күз кыса.
«Монда килә күрмәгез»,— дип,
Пароходка сүз куша.

Мәрзия Фәйзуллина.

?! Шигырьдәге маякта кеше сыйфатлары бар. Шуларны табыгыз.

ЯҢГЫР.

Яңгыр безнең тәрәзәгә
Чиертә дә чиертә.
Берәү дә ачып кертмәгәч,
Үпкәләп читкә китә.

Мәрзия Фәйзуллина.

?! Яңгыр кайсы яклары белән кешегә охшаган? Бала яңгыр үпкәләвен ничек белә?

Шигырьне дәвам итик. Яңгыр ява да ява. Тәрәзәдән карап утыручы баланы күз алдына китерегез. Менә сез үпкәләгән яңгырны кызгандыгыз һәм тәрәзә ачып өйгә керттегез, ди. Аннан соң ни була? Сез яңгыр белән ничек сөйләшерсез? Әниегез кайтып кергәч, ул ни ди? Яңгырның да үз әнисе бар — болыт. Ул да баласын эзләргә чыкмыймы? Шул хакта хикәя языгыз.

ҖИЛ.

Җил, укыйм диеп, китапның
Битләрен ача.
Укый белмәгәч нишләсен —
Ташлый да кача.

Мәрзия Фәйзуллина.

?! Шигырьне дәвам итегез.

САБАН ТУЕ.

Су яры.
Нарат урманы.
Шундый зур һәм куе ул.
Буенда гөр килә бәйрәм —
Безнең Сабан туе ул.
Менә мәйдан.
Әллә кайдан
Чуарланып күренә.
Бертуктаусыз уза халык
Шул мәйданның түренә.
Көрәш кыза,
Сизелмичә,
Кадерле вакыт уза.
Җиңүче батырга судья
Бүләккә сәгать суза.
Мәйданга кешеләр һаман
Тулганнан-тула тора.

Ярышлар,
Бәйге, чабышлар,
Уеннар булып тора.
Кукри, гөрли, тыну белми
Кара урман буйлары,
Ел да шулай матур уза
Безнең Сабан туйлары.

Мәхмүт Хөсәен.

?! Сабан туенда сезниләр күрдегез, шул хакта языгыз. Язмагызны укып күрсәтегез.

ПИРОГ ЭЧЕНДӘ КҮК БӨРТЕГЕ.

Төньяктагы салкын бер илдә карт белән карчык яшәгән. Кыш көннәренең берсендә карт карчыгына:

— Бүген көн бик салкын. Әллә алма пирогы пешерәсеңме? — дигән.

Карчыгы камыр изгән. Аны уклау белән җәя башлаган. Шулчак карты тәрәзәгә төртеп күрсәткән:

— Урамга кара әле, карчык, бүрек-бүрек кар ява,— дигән.

Карчык яуган карга сокланып карап торган арада, камырга күкнең кечкенә генә бер бөртеге килеп төшкән. Уклау аны шунда ук, тәгәри-тәгәри, камыр эченә кертеп куйган.

?! Укыган өлеш—әкияттәге беренче вакыйга. Аның безгә иң кирәкле урынын табыйк. Иң кирәк урыны —

тормышта була алмый торган хәл. Ә без авторның нәкъ менә шул урында безгә елмаеп карап торуын беләбез. Шул вакыйга турында сөйләгез.

Карчык камырын юка итеп җәйгән. Эченә алма салып, өстен камыр белән каплаган. Пирогын кайнар мичкә тыккан.

Күп тә үтмәгән, өй тәмле ис белән тулган.

Әби өстәлгә кашыклар, тәлинкәләр куйган. Мич капкачын ачкан... Шуннан соң ни булганын белсәгез, исегез китәр. Күк бөртеге пирогны җиппҗиңел иткән. Әби табагачын кулына алу белән, пирог мичтән чыккан да киткән.

— Тот, тот, өйдән чыгарма! — дип кычкырган карчык. Пирогының бер читенә ябышмакчы булган, ләкин ишек ачык икән, пирог бакчага очып чыккан.

— Сикер тизрәк өстенә! — дип кычкырган карт һәм тиз генә пирог өстенә менеп утырган. Аның артыннан әби дә сикереп менгән.

Пирог алар авырлыгын сизмәгән дә, күккә карап менгән дә менгән.

?! Бу өзектә дә автор безгә елмаеп торган вакыйга бар. Шул урынны табыгыз.

Нәкъ шул чакта ак тамгалы кара Песи, кар яуганын күзәтеп, алмагач ботагында утыра икән. Пирог шул тирәгә җиткәч, Песи дә әби белән бабай янына сикергән. Ләкин аска төшәсе урынга, пирог тагын да өскәрәк күтәрелгән.



— Кара нинди могҗиза! Пирог очып бара, өстенә әби, бабай, Песи утырган! — дип гаҗәпләнгәннәр кошлар.

— Нигә күктә очасыз? — дип тә сораганнар.

— Туктата алмаганга очабыз,— дип җавап биргән карчык. Шактый очкач, самолёт күргәннәр. Ул күктә бер урында туктап тора икән. Очучысы, мескен, бер урында утыра-утыра туңган, күшеккән.

— Кара-кара! Алма пирогы очып бара. Өстендә әби, бабай, Песи,— дип гаҗәпләнгән очучы. Аннары: — Нигә күктә очасыз болай? — дип сораган.

— Туктата алмыйбыз,— дип җавап биргән карчык.

— Самолётымның ягулыгы бетте. Мине дә үзегез белән алмассызмы? — дип үтенгән очучы.

— Сикер әйдә,— дигәннәр әби белән бабай.

Очучы самолётыннан пирог өстенә сикергән.

Беркадәр очкач, болыт өстендә утырган Үрдәк күргәннәр.

— Аптыраш. Алма пирогы оча, өстендә әби, бабай, Песи, очучы,— дип гаҗәпләнгән Үрдәк. Аннары ни өчен күктә очуларын сораган.

— Туктый алмаганга очабыз,— дип җавап биргән карчык.

— Очу кагыйдәләрен оныттым. Мине дә үзегез белән алмассызмы? — дип үтенгән Үрдәк.

— Утыр әйдә, урын җитәрлек! — дигәннәр әби белән бабай.

Үрдәк тә болар янына сикереп төшкән.

Бергәләп очканнар, очканнар, оча торгач, биек тау күргәннәр. Тау башында Тау кәҗәсе басып тора икән.

Ул да башта гаҗәпләнгән...

— Төшү юлын югалттым. Мине дә үзегез белән алмассызмы? — дип үтенгән.

Ул да пирог өстенә сикереп менгән.

Беркадәр очкач, зур бер шәһәргә барып җиткәннәр. Бик биек йортлар өстеннән очканда, берсенең түбәсендә Фил басып торганын күргәннәр. Аны да үзләре белән алганнар.

Фил авыр бит ул. Пирог бер якка кыйшая төшкән.

Алай да очуларын дәвам иткәннәр. Салкын кышлы илләр артта калган. Җылы якка килеп җиткәннәр. Аста зәп-зәңгәр диңгез, диңгез уртасында ямь-яшел утраулар күргәннәр.

?! **1.** Үрдәк тә, Фил дә пирогтагыларга сорау бирмәделәр. Алар нинди сорау бирергә тиеш иде?

2. Әле укып чыккан өзек озын булды. Анда автор берничә урында елмап тора. Шаяртуымны аңлыйсыз бит, әйеме, ди. Шул урыннарны табыгыз.

3. Өзектә вак-вак вакыйгалар бер-берсенә охшаганнар. Шуны аңлатыгыз.

4. Охшаган вакыйгаларны җыеп, бер генә вакыйгага калдырып әйтегез.

Оча торгач, пирог суынган. Шуңа күрә авырайган һәм түбән төшә башлаган.

— Әйдәгез, менә бу матур утрауга төшик! Мондагы ком ап-ак, агачлары ямь-яшел, чәчәкләре күп, бар да матурлар,— дигән карт.

— Төшик! — дип хуплаганнар аны карчык, Песи, очучы, Үрдәк, Тау кәҗәсе һәм Фил.

Ләкин утрауда яшәүчеләр боларның очканын ерактан ук күреп торганнар икән. Төшәргә җыенганнарын күргәч, эре хәрефләр белән язылган плакат күтәргәннәр. Ә анда «Пироглар тукталышы юк» дип язылган.

Башка бер утрауга очып, анда төшмәкче булганнар. Ләкин ул утрау кешеләре дә төшермәгәннәр. «Пирогларга төшү тыела» дип язган плакат күтәреп чыкканнар.

— Шулай ук төшәр утрау таба алмабыз микәнни?! — дип сукранган әби.

Пирог, түбәнәя-түбәнәя, диңгез өстенә утырган.

— Бик әйбәт булды. Пирог үзе бик матур утрау! — дигән карт.

— Монда бер генә агач та, чәчәкләр дә юк. Бу кадәр халыкны ничек туйдырмак кирәк?! — дип сукранган әби.

Әби пирог эчендә алма барлыгын онытып җибәргән икән... Кояш җылысында алма күз ачып йомганчы тишелгән. Үсә-үсә чәчәк атып җибәргән. Сәяхәтчеләребез сокланып торган арада, алмалар кызарырга да өлгергәннәр.

Тау кәҗәсе аларны сөте белән сыйлаган. Үрдәк йомырка салган, Песи диңгездән балык тоткан, Фил алмагачтан алмалар җыйган.

Утрауда бәхетле тормыш башланган.

Нәни күк кисәге пирог эченә кермәгән булса, мондый гаҗәп вакыйгаларның берсе дә булмас иде.

Джоан Эйкен.

?! Менә сез дә алма пирогына утырып, могҗизалар күреп йөрдегез. Нинди могҗизалар күрдегез? Сезгә аеруча кайсылары ошады?

Димәк, автор әсәрен язып кына калмый, анда катнаша да икән. Ләкин әсәрдә без — укучылар да катнашабыз. Ике төрле катнашабыз. Әсәрне ятламыйча, аның эчтәлеген үзебезчә сөйлибез.

Сүз һәм автор.

Авторның әсәр язучы булуын беләбез. «Сүз» эчтәлеген ачыклыйк.

Без ни әйтсәк тә сүздән файдаланабыз. «Мин ялкау түгел» дип мактану өчен өч сүз дә җитә. «Мин әтигә, әнигә, әбигә булышам» дию өчен өч кенә сүз җитми.



Сүз ул — бөтен нәрсәнең билгесе. «Ипи» сүзен ашап булмый, ә кибеттән сатып алган ипи бөтенләй башка. «Уку» сүзе беребезгә дә белем бирми. Ә китап уку — барыбызның да яраткан эше.

Нәтиҗә ясыйк. Сүзнең эчтәлеге бар. Кайберсе хәтта ике эчтәлеккә ия.

«Казан» сүзе, мәсәлән, шәһәр исеменә генә риза булмыйча, аш пешерә торган савытка үз исемен биргән: «Казан» дигән. Шуңа күрә ул — шәһәр дә, бер үк вакытта савыт та.

Татар телендә андый сүзләр бик күп. Алар белән алдарак танышырбыз әле. Ә хәзергә сүзнең күп санлы һөнәрләре белән танышуны дәвам итик.

Сүзнең усалы да, ямьсезе дә, матуры да, эшчәне дә, ялкавы да бар. Бер сүзне усал һәм шәфкатьле, матур һәм ямьсез итеп тә әйтеп була.

Дәреслектәге «Сүз һәм автор» битендәге рәсемне игътибар белән карагыз әле. Ни күрәсез? Күзлекле абзый бер сүздән бөтенләй башка сүз ясаган. «Бар, бар, бар» сүзләрен тезә торгач, «юк» сүзе килгән дә чыккан. «Бар» шунда ук «юк»ка әйләнгән.

Хәзер авторның ифрат әһәмиятле фикерен әйтик: ул ике дошман якны — юк белән барны дуслаштырган. Әсәрләрнең иң күп кабатланган төзелеше шундый.

Сүзнең тагын бер искиткеч матур сыйфаты белән танышыйк.

Кирәк дәшми-тынмый бер читтә терәлеп тора. Бер уңган бала килгәнен көтә. Икәүләп алар әллә ниләр эшли алалар бит.

Сүз дә шулай. Ул дәшми-тынмый бер читтә посып утыра. Бер бала икенчесенә «Булышыйммы?» сүзен әйтү белән, ул сүз шунда ук җанлана. Әле генә ялгыз утыра иде, хәзер алар икәү — сүз һәм ул сүзне әйткән бала.

«Булышыйммы?» сүзен ишеткәч, ярдәмгә мохтаҗ кеше шатлана. «Нинди шәфкатьле, игелекле бала»,— ди. Кулына кирәк тотып булышкан бала да сөенә. Ник сөенмәсен, ул ярдәм итте бит.

«Булышыйммы?» сүзе дә шатлана. Ник шатланмасын, берьюлы ике кешене шатландырды бит ул.

Мактап әйтелгән «Булдыклы» сүзен кемнең ишетәсе килми! Бик күп укучыны бәхетле итә бу сүз. Барысын да шатландырырга өлгермәсә, аңа ярдәмгә әйтемнәр килә.

- Таш астыннан чыккан.
- Ут уйната.
- Кулы кулга йокмый.
- Кулыннан гөл генә таммый.
- Буран уйната.
- Баскан эздән су чыгара.

Кылны кырыкка яра, дип мактыйлар әйтемнәр булдыклы укучыларны.

Әйтемнәрнең үзләренә дә булышам дип торучылар тулып ята. Укучы бер көн эчендә өч «биш»ле алды, ди. Шатлыгыннан башы түшәмгә тиде, ди

әйтем. Ләкин бу әйтемнәрнең дә ярдәмчеләре күп. Шулар арасыннан берсен үзегезгә ошаган башка әйтем белән алыштырыгыз.

- Башы күккә тиярдәй булды.
- Йөзе яктырып китте.
- Канатланып китте.
- Йөзе кояш булды.
- Кош токандай булды.
- Күңеле күтәрелде.
- Шатлыктан телен йотты.

?! Әйтемнәрне тагын өч тапкыр укып чыгыгыз. Китабыгызны ябыгыз. Хәтердә калганнарын әйтегез.

ЧИШМӘ.

Яр астыннан чишмә ага,
Челтер-челтер тавышы.
Җил искәндә иелеп кала
Читкә үскән камышы.

Челтер-челтер чишмәбез,
Ярдан балчык ишмәгез!
Суны шуннан эчегез,
Башка җирдән эчмәгез.

Муса Җәлил.

?! **1.** Шигырьдә катнашучыларны әйтегез.

2. Алар арасыннан ике иң әһәмиятле катнашучыны күрсәтегез. Аннан соң авторны һәм укучыны табыгыз.

3. Шигырь чишмә турында түгел. Тагын ни турында булырга мөмкин?

ТОРАМ МЕНӘ ЕЛМАЕП.

Әтиемнең малае
Бераз шаянрак.

Әниемнең малае
Бераз наянрак.

Әбиемнең оныгы
Бераз кирерәк.

Ә бабамның оныгы
Бераз эрерәк.

Абыемың энесе
Начаррак укый.

Сеңелемнең абыйсы
Артыграк йоклый.

....

Роберт Миңнуллин.

?! **1.** Шигырьдә шаян, наян, кире, эре, начар укый торган малайлар ничәү? Җавабыгызны күп нокталар урынына языгыз.

2. Алар әйбәтләрме, начарлармы?

Түбәндәге әйтемнәр белән танышып чыгыгыз.

- Борчак атарга яратам.
- Төп башына утыртырга яратам.
- Коелып төшәм.
- Котым алына.
- Эчем жу итеп китә.
- Аяклы каза.
- Аяк өсте йоклап йөри.

Әйтемнәрнең берсен сайлап алыгыз. Шулардан файдаланып, үзегезгә бәя бирегез. Шигырьдәге малайдан үрнәк алыгыз. Ул үзенең кимчелекләрен әйтүдән курыкмаган.

Бай сүзләр.

Бер сүз эчендә ике төрле эчтәлек булса, ул сүзләргә «бай сүз» дибез. Ничек бай булмасын, ди. Мәсәлән, «Чүлмәк» сүзендә чүлмәктән башка берни дә юк. Ә менә аның күршесе «Казан» сүзе эчендә шәһәр дә бар, аш пешерә торган казан да бар. Шулай булгач, бу сүзне ике өлешкә бүлеп була. Язучылар шулай итәләр.

Казан шәһәре берәү генә, ә өй казаны элек һәр йорт саен булган. Ләкин икесен дә «казан» дип йөрткәннәр.

Безнең борынгы бабайлар шундый каршылыкны тапканнар да «Үзе берәү генә, үзе өй саен» табышмагына җавап эзләгәннәр. Ул — «Казан» сүзе.

Әсәрне шулай да иҗат итәләр.

ҖӘЕН.

Күпме йөрсәк тә без
Җәен,
Каптыра алмадык
Җәен.

Шәүкәт Галиев.

?! Сүз байлыгын аңлатыгыз.

ТИЕННӘР.

Тәлгать тоткан бер тиен,
Мин Тәлгатьне үртимен:
— Менә сиңа ун тиен,
Бир син миңа бер тиен.
Тәлгать әйтә:
— Шаяртма,
Койрыгын тотма, тартма,
Кирәкми бер тиен дә,
Бирермен мин тигенгә.
Бирермен бүләк итеп,
Түләмичә бер тиен,
Карарсыз сез бер тиен.

Шәүкәт Галиев.

?! «Тиен» сүзе бай сүз. Шуңа күрә ул әсәрне ике өлешкә бүлә. Исбат итегез.

ЯРА.

Кара әле, кара:
Каен ЯФРАК ЯРА,
Каюм УТЫН ЯРА,
Кулларында — ЯРА.
Кыям бара-бара
Гел КӨНБАГЫШ ЯРА.

Бабай, шаулап кара,
ЧЫБЫК БЕЛӘН ЯРА.
Менә әйбәт чара —
Шәрәф ШӘРРАН ЯРА!

Роберт Миңнуллин.

?! **1.** Бу шигырьдә дә бай сүзләр күп. Шуларның байлыгын аңлатыгыз.

2. Төп катнашучыны әйтегез.

3. Шигырьне үз сүзләрегез белән сөйләп чыгу өчен сораулар:

а) Каюм кайчан утын яра?

ә) Кыям кайчан көнбагыш ярып бара, ә Шәрәф шаулап бара?

ТАПКЫР КЫЗ.

Бер бабайның җигә торган ике үгезе, мәдрәсәдә укучы бер кызы бар икән. Бабай көн дә арбасына үгез җигә. Урманга китә. Анда утын төяп, базарга юнәлә. Алар утын саткан акчага көн күрәләр икән.

Көннәрдән бер көнне утын төягән арба янына бер бай килә.

— Утыныңны сатасыңмы, бабай? — дип сорый.

— Сатам,— ди бабай.

— Ни хак?

— Биш тәңкә.

— Тулаем сатасыңмы? — дип сорый бай.

— Тулаем сатам,— дип җавап бирә бабай.

Өч мәртәбә тулаем сатам, дип әйттергәч:

— Әйдә, җитәклә үгезеңне, акча өйдә,— дигән бай.

Китәләр. Ишегалдына барып керәләр. Бай капканы яба. Өйгә кереп, бабайга биш сум чыгарып бирә.

— Үгезең дә, арбаң да, утының да минеке. Мин аларны тулаем алдым,— ди бай.

— Мин риза түгел. Әйдә казыйга,— ди бабай. Казыйга баралар.

— Мин моңа утын гына саттым. Ә ул үгезне дә, арбаны да бирми,— ди бабай.

— Тулаем сатасыңмы? — дип, мин аңа өч мәртәбә әйттердем,— ди бай.

— Алай булгач, бабай, гаеп итмә. Үгезең, арбаң, утының — барысы да байныкы,— ди казый.

Бабай елый-елый кайтып китә.

— Ник елыйсың, әти,— дип сорый кызы.

Бабай ни булганын сөйләп бирә.

— Бер дә кайгырма, әти. Безнең тагын бер үгез бар бит әле. Иртәгә дә базарга утын алып барыйк. Ләкин бай белән мин үзем сатулашырмын,— ди кыз.

Бабай иртәгесен утын төяп базарга килә. Үзе читтәрәк йөри.

Тагын теге бай килеп чыга.

— Кызым, утыныңны сатасыңмы? — дип сорый бай.

— Сатам. Хакы биш тәңкә,— ди кыз.

— Тулаем сатасыңмы? — дип сорый бай.

— Тулаем сатам,— ди кыз.

Бай кызны өенә алып кайта. Өеннән акча алып чыга да «мә» дип кулын суза.

Кыз тегенең кулыннан ныгытып тота да:

— Бу акчаны кулың белән бирдеңме? — дип сорый.

— Кулым белән бирдем,— ди бай.

— Кулың беләнме?

— Кулым белән.

Өч мәртәбә әйттерә кыз да.

— Кулың минеке, риза булмасаң, әйдә, казыйга барабыз,— ди кыз.

Казыйга җитәкләшеп баралар.

— Ни йомыш белән килдегез,— дип сорый таныш казый.

Кыз сөйләп бирә. — Кулым белән бирдем дип, өч мәртәбә әйттердем,— ди.

— Кулым белән бирдем дип, өч мәртәбә әйттеңме? — дип сорый казый.

— Әйттем,— ди бай.



— Алайса, кулың бу кызныкы. Кулыңны жәлләсәң, мең сум акча бир,— ди казый.

Бай мең тәңкәсен чыгарып сала.

?! **1.** Әкиятне ике вакыйгага бүлегез.

2. Икесенә дә исем бирегез.

3. Беренче вакыйгада бабайны бай ничек алдый?

4. Икенче вакыйгада кыз байны ничек җиңә?

5. Бай да, кыз да алдыйлар. Икесенә дә бәя бирегез: алар яхшылармы, яманнармы?

ПЕСИ.

Әти, песи алыйк әле!
Һәммәбез карар иде.
Әгәр дә песи булмаса,
Мәче дә ярар иде.

Роберт Миңнуллин.

?! **1.** Малайга әтисе кайсын алып кайтачак: песиме, мәчеме?

2. Бу шигырендә автор безгә ни табарга куша?

3. Сез дә шундый табышмак языгыз: исемен «Эт» дип куегыз. Шигырьне язып бетерегез.

Әти, эт алыйк әле!
Ул безне саклар иде.
Әгәр эт очрамаса,
... да ярар иде.

Охшаш сүзләр.

Искә төшерик. Сүзләр үзләренә охшаган башка сүзләр белән янәшә торырга яраталар. Бер-берсенә якын торган охшаш сүзләргә **рифма** диләр. Охшаш сүзләр әсәр эчендәге юлларны бәйләп торалар.

Охшаш сүзләр мәкаль һәм табышмакларда еш очрыйлар. Ә җырлар һәм шигырьләр рифмасыз, гомумән, яши алмыйлар. Сәләтсез сәнәк сындырыр, көчсез көрәк сындырыр, диелә мәкальдә.

Беренче юлда сүзнең өчесе дә «С» хәрефенә башлана. Андый сүзләргә «аз охшаганнар» диләр. Шул ук юлда икешәр авазы охшаган сүзләр дә бар.

?! **1.** Икенче юлдагы охшаш сүзләрне әйтегез.

2. Мәкальнең беренче юлын үз сүзләребез белән әйтик: сәләтсез бала, эшлим дип кулына сәнәк алса, сәнәгеН сындыра.

3. Мәкальнең икенче юлын да шулай үзгәртеп әйтегез.

МАКТАНА.

— Безнең холодильник ЗИЛ!
— Һм, Зилне без беләбез.
— Ә менә безнеке ҖИЛ —
Форточкадан эләбез.

Шәүкәт Галиев.

Рифмалы мәкальләр.

- Уйнап сөйләсәң дә,
  Уйлап сөйлә.
- Соң булса да, уң булсын.
- Аз да җитә, күп тә бетә.
- Күп сүзнең азы яхшы,
  Аз сүзнең үзе яхшы.

?! **1.** Мәкальләрне ике кат укып чыгыгыз. Китабыгызны ябыгыз. Ничә мәкаль истә калдырдыгыз, әйтеп карагыз.

2. Рифмага иң бай мәкальне күрсәтегез.

Рифмалы табышмаклар.

- Яшел-яшел пәриләр тәрәзәдән ... . *(Гөлләр.)*
- Үзе тауның кашында, яшел бүрке ... . *(Чыршы.)*
- Аяксыз-кулсыз капка ача, ача да артына ... . *(Җил.)*
- Үзе тигез, үзе такыр, бассаң ... . *(Су.)*

?! Нокталар урынына кирәкле сүзләрне табып куегыз.

Җырдагы рифма.

Су буена төшкән идем,
Су өсте күбек кенә;
Син бит минем якын дустым,
Күз нурым кебек кенә.

?! Охшаш сүзләрне табыгыз.

Әсәрне кыскартып сөйләү.

Сез барыгыз да хыялга бай, уйлый белә торган балалар. Нигә әле үзегезгә дә могҗизалар уйлап чыгарырга өйрәнмәскә?!

Могҗиза беренче чиратта берәүне дә кабатламаган өр-яңа уйдан башлана. Кеше әйткәнне кабатламый торган фикернең исеме дә бик матур: аңа **иҗади фикер** диләр. Әйдәгез, иҗади фикерләргә өйрәник.

Кыскартып сөйләргә өйрәнү нигә кирәк?

Кыскартып сөйләгәндә, ятлаганны кабатламыйбыз. Вакыйгаларны үз сүзебез белән әйтеп бирәбез. Әсәрне ничек кыскартыйк?

Әсәрдә төп герой һәм ул катнашкан төп вакыйгалар була. Шуңа күрә иң элек төп өлешне табарга өйрәник.

Әсәрне кыскартып сөйләү өчен, төп катнашучыларны һәм алар катнашкан вакыйгаларны гына истә тотарга кирәк.

Охшаш вакыйгаларны кушып, бергә генә калдырып сөйләү дә кыскарту була.

УНГА КАДӘР САНЫЙ БЕЛӘ ТОРГАН КӘҖӘ БӘРӘНЕ ТУРЫНДА.

Унга кадәр саный белә торган Кәҗә бәрәне яшәгән. Бермәлне ул күл янына килгән. Тонык суда үзен күреп шаккаткан. Суда чагылган йөзенә карап-карап торган да, менә ни булган...

— Берәү! — дигән Кәҗә бәрәне.

Аның санаганын Бозау ишеткән. Ул якында гына үлән чемченеп йөри икән.

— Син нишлисең? — дип сораган Бозау.

— Мин үземне үзем санадым. Сине дә санsocialиммы? — дигән Кәҗә бәрәне.

— Авырттырмый торган булсаң сана соң,— дигән Бозау.

— Нишләп авырттырсын, бер дә авырттырмый. Тик селкенмичә генә тор. Селкенсәң саный алмыйм,— дигән Бәрән.

— Кит әле. Куркам мин. Әни дә рөхсәт итмәс,— дигән Бозау һәм артка чигенгән.

Ләкин Бәрән Бозау каршына килеп баскан да:

— Мин — берәү, син — икәү. Берәү, икәү,— дигән.

— Әни-и-и,— дип, кызганыч тавыш белән кычкырган Бозау.

Аның тавышын Сыер ишеткән. Муенына кыңгырау таккан Сыер шунда ук чабып килгән.

— Му-у-у, нигә елыйсың? — дип сораган Сыер.

— Мине Кәҗә бәрәне санады,— дип зарланган Бозау.

— Ни ул санау? — дип, ачу белән сораган Сыер.

— Мин унга кадәр санарга өйрәндем. Санап күрсәтәм, тыңлагыз: Берәү — ул мин, икәү — ул Бозау, өчәү — ул Сыер. Берәү, икәү, өчәү,— дип санап күрсәткән Бәрән.

— Күрдеңме? Ул бит сине дә санады! — дигән Бозау. Аңлап алгач, Сыерның бик тә ачуы чыккан.

— Син әле безне мыскыл итәсеңме? Әйдә әле, Бозау, тетмәсен тетик шуның! — дигән һәм, Бозавын ияртеп, Бәрәнне куа киткән. Бәрән куркуыннан кая басканын да белми чапкан.

Бер Үгез куак тамырларын мөгезе белән актарып йөри икән. Боларны күреп каршыларына төшкән.

— Нигә куасыз бу өтек койрыкны? — дип сораган Үгез.

— Ул безне саный,— дип, елый-елый зарланган Бозау.

— Барыбер тотып тетмәсен тетәбез без аның,— дигән Сыер.

— Берәү — ул мин, икәү — ул Бозау, өчәү — ул Сыер, дүртәү — ул Үгез. Берәү, икәү, өчәү, дүртәү,— дип санап киткән Кәҗә бәрәне.

— Мине дә санадыңмы? Миннән болай гына котыла алмассың! — дип мөгрәгән Үгез, һәм ул да куучыларга ияргән.

Куа-куа олы юлга чыкканнар. Юл читендә Ат үлән кыркып йөри икән. Юл тузанын ул ерактан ук күреп алган.

— Кая ашыгасыз болай? — дип кычкырган Ат.

— Кәҗә бәрәнен куабыз. Ул безнең барыбызны да санады,— дип җавап биргән Сыер.

— Ул безне саный,— дип кушылган аңа Бозау.

— Ни хакы бар аның безне санарга? — дигән Үгез, уфылдый-уфылдый.

— Ничек саный соң ул сезне? — дип сораган Ат.

— Менә болай,— дигән Бәрән һәм санап күрсәткән.

— Берәү — ул мин, икәү — ул Бозау, өчәү — ул Сыер, дүртәү — ул Үгез, бишәү — ул Ат. Берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү!

— Менә күрдеңме, Бәрән сине дә санады,— дип зарланган Бозау.

— Ах, юньсез. Син әле шулай мине дә санадыңмы? Миннән ерак кача алмассың! — дип кешнәгән Ат һәм тизлеген арттырган.

Читтәрәк Дуңгыз йоклап ята икән. Тояк тавышыннан уянгач, ул да:

— Мырк-мырк-мырк! Болай җыйнаулашып кая чабасыз? — дип кызыксынган һәм болар артыннан ияргән.

— Кәҗә бәрәнен куабыз,— дигән Сыер.

— Ул безне саный,— дигән, кызганыч тавыш белән, Бозау.

— Ни хакы бар аның безне санарга, уф-ф! — дип үкергән Үгез.

— Тотып кирәген бирәбез без аның! — дип кешнәгән Ат.

— Ничек санады? — дип сораган Дуңгыз, башкалардан артта калмаска тырышып.

— Санауның бер кыенлыгы да юк,— диган Бәрән һәм: — Берәү — ул мин, икәү — ул Бозау, өчәү — ул Сыер, дүртәү — ул Үгез, бишәү — ул Ат, алтау — ул Дуңгыз, — дип санап күрсәткән.

— Менә күрдеңме? Бәрән сине дә санады бит! — дигән Бозау, еларга җитешеп.

— Измәсен изәм мин аның санаган өчен,— дип мыркылдаган Дуңгыз, һәм ул да, тизлеген арттырырга тырышып, Бәрәнне куа киткән.

Чапканнар, чапканнар, юл димәгәннәр, тау димәгәннәр — барысын да кичкәннәр. Чаба торгач, елга ярына килеп җиткәннәр. Ярга борынын төртеп, җилкәнле көймә терәлгән икән. Көймә борынында Әтәч, Эт, Сарык һәм Песи басып торуын күргәннәр. Капитаннары Әтәч икән.

— Кая чабасыз, туктагыз! — дип кычкырган Әтәч, бер көтү хайван килүен күреп.

Ләкин аңа берәү дә игътибар итмәгән. Көймәгә иң башта Кәҗә бәрәне сикереп менгән, аның артыннан башкалары. Көймә, чайкала-чайкала, елга уртасына кереп киткән. Бу хәлне күргәч, Әтәчнең коты очкан.

— Кикрикүк! Батабыз. Ярдәм итегез! — дип кычкырган капитан.

Куркудан барысы да елар дәрәҗәгә җиткәннәр.

— Кайсыгыз саный белә? — дип, бөтен елга буен яңгыратып кычкырган Әтәч.

— Мин саный беләм,— дигән Кәҗә бәрәне.

— Алайса, безне тизрәк санап чык. Көймә ун пассажир гына утырта ала. Артык булса бата!

— Сана, тизрәк барыбызны да санап чык! — дип кычкырганнар пассажирлар.

Кәҗә бәрәне санарга керешкән:

— Берәү — ул мин, икәү — ул Бозау, өчәү — ул Сыер, дүртәү — ул Үгез, бишәү — ул Ат, алтау — ул Дуңгыз, җидәү— ул Песи, сигез — ул Эт, тугыз — ул Сарык, ун — ул Әтәч.

— Яшәсен Кәҗә бәрәне? Ура-а-а! — дип кычкырган бар да.

Җилкәнле көймә исән-имин аргы ярга җитеп борынын төрткән. Бар да ярга сикергәннәр. Ә Кәҗә бәрәнен көймәдә калдырганнар. Ул анда контролёр булып эшли икән. Көймәгә утыручыларны бер дә саташмыйча санап чыга икән.

Алф Прёсн.

?! Әкиятне болай кыскартып була: кәҗә бәрәне нинди бәхетле. Ул үзенең саный алуына куана. Белеме аркасында тормышта үзенә җайлы гына эш таба. Бозау бозау инде ул. Сыер белән үгез, нинди зурлар булсалар да, надан калганнар. Шуңа күрә үзләрен санаудан да куркалар. Икенче өлеш, киресенчә, кәҗә бәрәнен мактау турында. Аны болай кыскартыйк: Куркак хайваннар санауның файдасын күрәләр. Бар да бәрәнне мактыйлар, санаудан курыкмый башлыйлар.

Әкиятне үз сүзләрегез белән сөйләгез.

ФИЛ, УЧАК ҺӘМ АК ҮРДӘК ТУРЫНДА.

Бик дәү, шулкадәр иләмсез, ләкин ифрат шәфкатьле бер фил яши. Аны Лони дип йөртәләр.

Бермәлне ул ял булыр, аяклар язылыр дип йөрергә чыга. Бара, бара, дөрләп янучы Учак янына килә. Ут янында Миранда исемле ак үрдәк җылынып утыра, ә читтәрәк түп-түгәрәк буа ялтырап ята. Учакның биек ялкыны буада көзгедәгедәй чагыла.

Лони туктый. Учак утына һәм ак үрдәкнең матурлыгына соклана. Ләкин көтмәгәндә каяндыр бер болыт килеп чыга. Яңгыр сибәли башлый. Бу хәлдән Учак куркып кала.

— Яңгыр ява башласа, мин үләм бит,— ди.

— Елама, еласаң, үзеңне үзең күз яшьләрең белән сүндерерсең,— дип юата аны Миранда.

— Тырышып карармын,— дип җавап бирә Учак.

— Кайгырма, ахирәт,— ди Лони һәм Учакка өрә башлый. Уты кабынгач, Учак тынычлана. Ләкин яңгыр көчәйгәннән-көчәя бара. Лони өрүеннән туктый да Мирандага әйтә:

— Тизрәк болытка очып мен. Әгәр хәзер үк яңгыр яудыруын туктатмаса, мин аңа шундый итеп өрермен, кая барыр тишек таба алмас,— ди.

Үрдәк Болытка очып менә. Фил кушканны сөйләп бирә.

Гафу итә күр инде. Сине күргәч, үрдәк суда чупырдарга ярата, дип уйладым. Яңгыр астында

кәефе булыр дип яңгыр койдым. Бу хатамны бүтән кабатламам,— ди Болыт.

Миранда, рәхмәт әйтеп, җиргә әйләнеп кайта. Ә Болыт башка якка очып китә.

Лони Учакка өрә дә өрә. Ниһаять, ут кабынып китә. Учак элеккедән дә куәтлерәк дөрләп яна башлый. Учак бик тә канәгать була. Ләкин аның каравы үрдәкнең кәефе китә.

— Сиңа ни булды? — дип сорый Лони.

— Мин..., мин... яңгыр яратам. Без үрдәкләр барыбыз да яңгырсыз яши алмыйбыз,— ди Миранда.

— Юкка хәсрәтләнәсең,— ди Лони. Озын хортумын буага чумдыра да күп итеп су суыра. Аннары үрдәккә чып-чын яңгыр яудыра.

— Чып-чын яңгыр! Хәтта чын яңгырдан да яхшырак! — дип шатлана үрдәк.

Лони тагын буадан су суырып ала. Тагын чып-чын яңгыр яудыра. Аннары тирән итеп сулыш ала да Учакка өрә.

— Хушыгыз,— ди Лони һәм китә. Миранда аны күзе белән озатып кала. Лони кечерәйгәннән-кечерәя бара. Бераздан бөтенләй күздән югала. Миранда учакка чыбык-чабык ташлый да башын канат астына куеп йокларга ята.

Төшендә ул, шундый дәү, әллә ни чибәр булмаса да, ифрат шәфкатьле Лонины күрә.

Дональд Биссет.

?! Әкияттәге вакыйгаларның барысында да фил әле учакка, әле үрдәккә ярдәм итә. Шуңа күрә әкият филнең шәфкатьлелеге турында дия алабыз. Кыскартып сөйләү ул — әсәрнең иң мөһим вакыйгасына игътибар итү. Ә охшаган вакыйгаларны кушып (гомумиләштереп) әйтергә кирәк була. Шулай итегез: әкиятне кыскартып сөйләгез.

КУШУЧ ШИКӘР.

— Хәерле иртә, күрше абзый! Йомыш белән кергән идем...

Кәрлә Джеромның чырае сытылды. Тоталар да әҗәт сорап керәләр. Әҗәткә бирергә яратмавымны белсәләр дә керәләр. Үзенең гөмбәгә охшаган йортында тыныч кына яшәп ята Кәрлә Джером. Бераүне дә борчымый. Бераүгә дә йомышка керми. Җәй буе запас җыя-җыя да кышын ашап бетерә. Ни өчен күршеләре дә шулай итми? Аларга әле он, әле йомырка, әле бал, әле борыч кирәк... Әҗәт сорап керәләр дә керәләр.

Бу юлы кергән бала күршедә яшәүче Кондызның кече улы икән.

— Ни кирәк, үскәнем? — дип мыгырданды Кәрлә.

— Сезне бөтен авыл игелекле дип мактый. Әни торт пешерә. Әҗәткә бер кило он сорарга кушты,— диде бала.

Кәрлә Джером яшел калфагын төзәтте дә:

— Бер кило он! Кычкыртып талау бит бу. Бер кило он! Кайчан кайтарасыз соң сез ул онны? — дип сорады.

— Әни чәршәмбе көнне базарга бара. Кайту белән кертәчәк,— дип сүз бирде Кондыз улы.

Кәрлә, теләр-теләмәс кенә, ян бүлмәсеннән бер төргәк он чыгарып бирде. Төргәге үзеннән дә биегрәк иде. Кунак төргәген көч-хәл белән күтәреп кайтып китте.

Саран Кәрлә ишеген бикләде. Төрепкәсен кабызды да янган мич алдына китап укырга барып утырды.

Бераздан тагын ишек шакыдылар.

— Кем бар?

— Мин, Кондыз малае.

«Кара син аны! Әҗәтен кертеп тә килә!» — дип шатланды Кәрлә.

Ләкин Кондыз улы йомырка сорарга кергән булып чыкты.

— Әни торт пешерә. Әҗәткә кечкенә генә булса да, йомырка бирүегезне үтенде,— диде.

— Әниең тортын ни салып пешерә? Бррр...

«Йомырка бирәсе урынга арт ягына берне бирәсе иде бит юньсез малайның — алай итсәң, әҗәткә алган онны кайтармаслар»,— дип уйлады Кәрлә. Йомырканың иң бәләкәен, чыпчык йомыркасын гына биреп җибәрде.

Кунак шатланып чыгып китте. Кәрлә Джером ишеген бикләп алды. Төрепкәсен кабызды. Китап укырга дип, янган мич алдына барып утырды.

Бераздан тагын ишек шакыдылар. Бу юлы күрше улы, торт эченә салырга дип, баллы кура җиләге сорады.

Кәрлә, ян бүлмәгә кереп, ишеген япты. Ачудан яшел калфагын башыннан алып җиргә бәрде.

«Их, бу юньсезне, якасыннан тотып, урамга атарга! Ярамый. Алай итсәң, әҗәткә алган онны да, йомырканы да кайтармаячаклар. Нишләргә? Әһә, уйлап таптым. Күрсәтим әле үзләренә баллы торт!» — дип уйлады Кәрлә.

Малайга татлы кура җиләге урынына ачы мүк җиләге тоттырды.

Кәрлә ишеген бикләде. Төрепкәсен кабызды, тагын китап укырга утырды.

Берничә минуттан Кондыз улы тагын ишек кагып керде. Бу юлы ул бер кушуч шикәр сорады.

— Әни торт пешерә,— дип кабатлады.

Сабырлыгы тәмам беткән Кәрлә ян бүлмәгә ашыга-ашыга керде. Чыккач, балага зур төргәк тоттырды. «Төргәк тулы тоз булуы башларына да килмәс. Тортлары авызга капмаслык булыр. Аның каравы әҗәт сорап йөдәтмәсләр»,— дип уйлады Кәрлә.

Күрше баласы киткәч, Кәрлә Джером ишеген ныклап бикләде. Борын астыннан гына нидер мыгырданды. Китабын алып утырды.

Тагын ишек шакыдылар. Ишеген ачып җибәрсә — каршында Кондызның бөтен гаиләсе басып тора.

— Хөрмәтле күршебез! Без сине туган көнең белән тәбриклибез. Бәйрәмеңне котлап бүләк китердек. Менә сиңа торт! Тәмләп аша! — дип, күршеләр барысы бергә елмаеп, Кәрләгә торт суздылар.

Кәрлә Джером һушыннан язды.

Х. А. Ланглесия.

?! Әсәрне кыскарту өчен, төп катнашучыларны тапкан идек. Алар икәү — Кәрлә Джером һәм кондызлар гаиләсе.

Аннары төп катнашучыларга бәя биргән идек. Бу юлы да шулай итик.

1. Башта Кәрлә Джеромга бәя бирегез.

2. Кондызлар гаиләсенә бәя бирегез.

3. Кабатланган вакыйгаларны кушып әйтегез.

4. Хәзер әкиятне кыскартып сөйләгез.

5. Кәрлә, тортның үзенә бүләк булуын белгәч, һуштан яза. Ни өчен һуштан язып егыла?

6. Автор безгә бу әсәре белән ни әйтә?

а) Усал, саран булсаң, көлкегә калырсың, диме?

ә) Кешегә бәя бирергә ашыкма. Яман кеше дигәнең яхшы, яхшы дигәнең яман булырга мөмкин, диме?

Кечкенә генә әсәрдән дә әнә никадәр нәтиҗә чыгара алабыз. Сәнгать әсәренең бер могҗизасы шуннан гыйбарәт.

КЫЗ БАЛА БЕЛӘН ЕЛАН.

Бик күптән бу дөньяда бер хәерче кызчык яшәгән. Ул бик саран, юньсез байның малларын караган. Иртә таңнан торып, караңгы төшкәнче эшләгән. Йокысыннан уяну белән, сыерлар абзарына чапкан. И ул мал карауның авырлыгы! Чыпчык чүпләп бетермәслек аның эше! Сыерларны ашаткан, эчерткән, сауган. Ә үзе көннәр буе ачлы-туклы йөргән. Хуҗасына зарланып бер генә сүз дә әйтмәгән. Көн яктысында эшләгән, төннәрен елап үткәргән. Үзенең хәсрәтен сыерларына гына сөйли торган булган.

Көннәрнең берендә кыз сыер саварга утырган. Кинәт аяк астында салам кыштырдавын ишеткән. Иелеп караса — башына алтын таҗ кигән Елан шуышып килә икән. Кызчык бик курыккан. Ләкин Елан аны чагарга уйламаган да. Шуышып башын күтәргән дә сөт чиләге эченә караган. Тамагы ач икән мескенкәйнең, дип уйлаган кызчык. Чиләген аудара төшеп, Еланга сөт эчерткән.

Сөт беркадәр кимегән. Ә хуҗа хатыны иреннән дә усалрак икән. Савылган сөтнең тамчысына кадәр исәпләп торган.

Кызны хуҗа ачуланып кына калса бер хәл әле, эштән үк куып чыгаруы бар бит.

Хуҗа хатын сөт кимүен шунда ук күреп алган. Кызчыкны карак дип, бик каты сүккән. Кызчык елаган, ләкин Елан турында ләм-мим бер сүз дә әйтмәгән.

Елан икенче көнне дә сөт эчәргә килгән. Бу юлы да ялчы кызга күтәрелеп караган. Күз төпләренең кып-кызыл булуын күргән.

Хуҗа хатын чиләктәге сөтнең кимүен белгәч, ялчысын бу юлы да карак дип сүккән, тукмап та алган. Кызчык елаган, ләкин Елан турында ник бер сүз ычкындырсын.

Елан өченче көнне дә килгән. Кызга күтәрелеп караган. Куллары, битләре күгәреп чыкканын күргән.

— Ни булды? — дип сораган Елан.

— Хуҗам ачулана. Сөтең аз дип кыйный. Нишләргә дә белмим,— дигән кызчык.

— Бер дә хәсрәтләнмә, бүтән ачуланмас,— дигән Елан һәм салам астына кереп югалган.

Ул көнне сөтен чүлмәкләргә бушатканда, кызчыкның исе-акылы киткән. Бушаткан саен, чиләгендәге сөт кимеми — арта гына бара икән. Ул көнне сауган сөт башка көннәргә караганда ике чүлмәккә артык булып чыккан. Хуҗа хатын шатланган. Йөзе яктырып киткән.

Алтын таҗлы Елан көн дә килгән. Тамагы туйгач, кызга рәхмәтле күзе белән карап торырга яраткан. Кызчык аның игелекле дус булуына ышанган. Дусты янында чакта ул бар хәсрәтен, җәфаларын оныта торган булган. Ә чиләктәге сөт артканнан-арта барган.

Вакыт узган. Кызчыгыбыз тирә-юньдә иң чибәр кыз булып үсеп җиткән. Өстәвенә шәфкатьле, игелекле дә икән. Аны бар да яратканнар. Ә бер эшчән яшь егет башкалардан да ныграк яраткан. Кызның да аңа күзе төшкән. Шуңа күрә егеткә кияүгә чыгарга ризалыгын биргән.

Ә икенче көнне алтын таҗлы Елан шуышып килгән дә кызга:

— Мин — тылсым иясе. Син мине ач үлемнән коткардың. Мине явыз сихерче карчык еланнар патшасына әйләндерде, улымны күбәләк итте. Минем улыма кияүгә чыгарга риза буласыңмы? Гомерең буе байлыкта, бәхетле булып яшәрсең,— дигән.

— Ышанычың өчен бик рәхмәт. Ләкин теләгеңне үти алмыйм, сүз биргән егетем бар,— дип җавап биргән кыз.

— Ихтыярың,—дигән Елан. Саубуллашкан. Шуышып чыгып киткән.

Туй көне дә килеп җиткән. Кунаклар җыелган. Бар да шатланып, җырлашып утырганда, кинәт күбәләк күче якынлашуын күргәннәр. Алда дүрт күбәләк ал ефәккә төрелгән арба тарта, ә арбада еланнар патшасы белән улы утыра икән. Ул арада шөпшәләр килен башына туй таҗы кидергәннәр. Алтын таҗлы Елан кыз җилкәсенә менеп яткан. Башындагы алтын таҗын кыз алдына куйгач:

— Игелегең һәм байлыкка кызыкмавың белән миннән һәм улымнан сихерне алдың. Шуның өчен сиңа туй бүләгем шушы таҗ булсын,— дигән.

Ефәкле арбасына утыру белән, Елан гүзәл хатынга, улы чибәр егеткә әверелгәннәр. Очып килгән күбәләкләр һәм шөпшәләр урынында хезмәтче егетләр, кызлар басып торганын күргәннәр. Кунаклар кияү белән киленгә баш игәннәр дә кайтып киткәннәр.

Килен бүләк алтын таҗны, истәлек булсын дип, тартмага салып куйган. Шул көннән алып тартма бер генә минут та акчасыз тормаган. Күпмесен ярлыларга өләшкән, күпме әйбер сатып алган, ләкин тартмадагы акча аз гына да кимемәгән. Алган саен арта гына бара икән.

Ярлы ялчы кыз менә шулай авылларында иң бай һәм иң бәхетле хатынга әйләнгән.

?! Кыскартып сөйләү өчен, әсәрнең иң әһәмиятле өлешен табарга кирәк.

1. Төп геройларны табыгыз.

2. Аларга бәя бирегез.

3. Охшаш вакыйгаларны кушыгыз. Аларга уртак исем бирегез.

НАМУС.

Борын-борын заманда бер бабай яшәгән. Балалары күп булган. Алар бергәләп басуда эшләгәннәр. Бергә утырып ашаганнар, хәсрәтләрен һәм шатлыкларын җыйнаулашып уртаклашканнар. Шуңа күрә бу гаилә нужа күрмәгән, тату гына гомер иткән.

Көннәрнең берендә бабай иртән торып тышка чыкса күрә — бөтен дөнья ап-ак карга күмелгән. Шулвакыт ат абзарының капкасы янында ниндидер ят эзләр барлыгын күреп алган. Кунак-фәлән күренмәде, балалар бар да өйдә йоклап яталар, дип аптырашта калган бабай. Күп уйлап тормаган, эз буйлап киткән.

Капкасын ачып урамга чыккан, авыл аша узган, басуга барып җиткән. Эз басу уртасындагы гөлҗимеш куагы янында юкка чыккан.

Бабай куак каршына килеп баскан да:

— Бүген берәү өйдән чыгып монда килгән. Эндәш! Кем син? — дигән.

— Өеңне мин ташлап чыктым. Мин — синең Бәхетең. Инде эзләп тапкансың икән, әйт, җаныңа кайсы якынрак: малмы, җирме, затлы киемме? Шул теләкләреңнең берсен генә үтим дә башка йортка күчәм,— дип җавап биргән Бәхет.

— Бер үтенечем бар, кайтып гаиләм белән киңәшергә рөхсәт ит,— дип сораган бабай.

— Тизрәк әйләнеп килсәң көтәрмен,— дигән Бәхет.

Бабай, ашыга-ашыга, өенә кайткан. Гаиләсенә Бәхет китүен һәм аның бабайга куйган шарты турында сөйләп биргән.

Бергәләп киңәш корганнар.

Өлкән кеше буларак, үз теләген башта бабайның карчыгы әйткән:

— Күбрәк җир сора, мул уңыш җыеп алырбыз, тамагыбыз тук булыр,— дигән.

— Бәлки, чаптар атлар сорарсың? — дип киңәш иткән өлкән улы.

— Затлы кием һәм муенсалар бүләк итсә, яхшы булыр иде,— дип, сүзгә кушылганнар бабайның кызлары.

Моңа кадәр яшь киленнең бервакытта да башкалар сүзенә катнашканы булмаган. Көтмәгәндә ул да тавыш биргән:

— Намус сорасаң, яхшы булыр иде, әткәй,— дигән.

— Бик дөрес әйтәсең, килен,— дип шатланган бабай.

— Шундый матур теләк нигә минем башыма килмәде икән? — дигән бабайның карчыгы. Уллары белән башка киленнәре дә бу теләкне бик хуплаганнар. Бабай басудагы куак янына чапкан.

— Бик озак киңәштегез. Йә, гаиләң ни сайлады? — дип сораган Бәхет.

— Малны да, җирне дә, киемне дә ал. Тик, зинһар өчен, Намусны калдыра күр,— дип җавап биргән бабай.

— Болай булгач, өегезгә кире кайтам. Намус кайда — мин шунда бит,— дигән Бәхет.

Бәхет әйләнеп кайткач, бабай гаиләсе элеккеге кебек, нужа күрми тату яшәгән.

?! Әсәрне болай кыскартып була: бәхет гаиләне сыный. Беренче өлештә ул йорттан китә. Әсәрнең икенче өлешендә ул өйгә кире кайта, чөнки бу йортта намуслы кешеләр яшәвен белә.

1. Ни турында? Тагын ни турында? дип, үзегезгә сорау бирегез һәм әсәрне ике өлешкә бүлегез.

2. Әгәр Бәхет тагын бер теләкне үтәргә риза булса, сез ни сайлар идегез?

Хәтердә калдырыйк. **Намус ул — кеше хөрмәтенә лаеклы булып яшәү.**

Бәхетле кеше ул — намуслы кеше, ди безгә әкият авторы. Димәк, кеше хөрмәтенә лаеклы булу — үзе бәхет дигән сүз.

УРМАН ПАТШАСЫ.

Бик күптән булган вакыйга бу. Ул чакта әле таулар да менә болай гына булганнар. Диңгез дә үзе менә моннан гына, ә үзе япь-яшь булган.

Ул чакта бөтен җирне урман каплаган булган. Бар җирдә урман да урман... Җир тулы урман. Урман тулы җәнлекләр, ә кешеләр юк. Әйтәм бит, бик-бик күптән булган хәл бу.

Урманда җәнлекләрнең зурлары, бәләкәйләре дә, көчлеләре, көчсезләре дә, усаллары, шәфкатьлеләре дә күп булган. Көчле усаллары көчсезләрен кыерсытканнар. Көчсезләр каршы әйтмәгәннәр. Курыкканнар.

Бермәлне зур усал җәнлекләр болай дигәннәр:

— Без бу урманның хакимнәре. Шуңа күрә барыгыз да безгә буйсынырга тиешсез, сезне ашар өчен, артыгыздан чабып арыдык. Бүгеннән соң без ашарга теләгән һәр җәнлек яныбызга үзләре теләп килергә тиеш. Без ашарга утырган саен, берегез килсен. Безнең боерык шундый.

Кем әйткән?

Бүре әйткән. Крокодил да әйткән. Күзлекле Елан да шуны ук кабатлаган.

Көчсез, шәфкатьле җәнлекләр элек тә бәхетсез булганнар. Аларны зур усал җәнлекләр өзлексез рәнҗетеп, кыерсытып торганнар. Ләкин элек көчсезләр качып котыла алганнар.

Хәзер аларга качу тыелган. Кечкенә җәнлекләр кайгыга төшкәннәр. Кайгылары шулкадәр зур булган, хәтта куркуларын да онытканнар.

— Зур усал җәнлекләр үзләрен урманның хаким-патшасы дип игълан иттеләр. Хаким-патша булырга аларның бер хаклары да юк. Алар безне үз теләгебез белән үлемгә барырга кушалар. Гаделсезлек бу! — дигәннәр. Болай яшәп булмый. Бу мәсьәләне хәл итик.

— Бу усаллыкка юл куймаска кирәк. Без ни дә булса эшләргә тиеш,— дигәннәр көчсез шәфкатьлеләр.

Кем әйткән?

Тычкан әйткән. Куян, Болан, Керпе, Маймыл, Тиен әйткән. Ләкин алар ни эшләргә кирәклеген белмәгәннәр.

— Бәхәсләшү файдасыз. Сез буйсынырга тиешсез. Хаклымы без, юкмы, ләкин без әйткәнчә булачак. Без урманның хаким-патшалары. Без сездән көчлерәк. Менә шул,— дигәннәр зур усал җәнлекләр.

Мәче башлы ябалак — ай-һай акыллы кош! Ул болай дигән:

— Безнең арадан көчлеләрне җиңәрлек кем бар? Җиңсә, урманга ул хаким-патша булыр иде. Ул безне тотып ашамас иде.

Бар да шатланганнар.

— Бик матур фикер әйтелде. Болан барыбыздан да зуррак. Усал җәнлекләр белән көрәшергә ул китсен. Болан аларны җиңәчәк. Урманның

хаким-патшасы булачак. Шуннан соң тыныч гомер итәрбез,— дигәннәр.

Болан зур һәм мөгезле. Ләкин артык юаш:

— Минем кыюлыгым җитми. Алар мине шунда ук ашарлар. Мин куркам,— дигән.

Мәче башлы ябалак ай-һай акыллы да инде.

— Иң гәүдәлене сайламыйк, иң кыюны сайлыйк. Кем кыю? Кем явыз җәнлекләр белән ярышырга тели? — дип сораган.

— Мин булдыра алмыйм,— дигән Төлке.

Маймыл да, Тиен дә, Куян да, Тычкан да шулай дигән. Бар да: «Мин түгел!» — дигәннәр. Бар да курыкканнар.

Кырмыска уртага чыгып баскан да:

— Зур усал җәнлекләр белән мин көрәшкә чыгам,— дигән.

Бар да пырхылдап көлеп җибәргәннәр.

— Тырнак очы кадәрле Кырмыскагамы соң аю-бүреләрне җиңү,— дигәннәр.

— Көлмәгез,— дигән Кырмыска.— Дөрес, аларны мин үзем генә җиңә алмыйм. Ләкин без күбәү. Без зур усал җәнлекләрне бергәләп җиңәчәкбез. Мин көчлеләрдән курыкмыйм,— дигән.

Шулай дигән дә Кырмыска зур усал җәнлекләр янына киткән.

— Сез үзегезне хаким-патша дип уйлыйсыз. Бездән дә көчлерәк җәнлекләр юк дип мактанасыз. Ялгышасыз. Кырмыскалар сездән көчлерәк,— дигән.

Зур җәнлекләр Кырмыскадан кычкырып көлгәннәр:

— Тырнак очы кадәр генә бит син! — дигәннәр.

— Мактанып утырмагыз. Әйдәгез, кайсыгыз безнең белән көрәшкә чыга. Синме, Бүре? Йә, көчеңне күрсәт! — дигән.

Бүре урыныннан сикереп торган да авызын киереп ачкан. Якындагы шомырт агачы кәүсәсен бер минутта чәйнәп өзгән.

— Менә нинди минем көчем. Хәзер сез көчегезне күрсәтегез,— дигән.

— Күрсәтербез,—дигән Кырмыска. Урмандагы барлык кырмыскаларны чакырган. Күп тә булганнар соң кырмыскалар! Бик күп булганнар. Алар бөтенесе берьюлы якындагы агачларга ташланганнар. Минут эчендә барысын да кимереп аударып та ташлаганнар.

Төлке урыныннан сикереп торган. Үткен тырнаклары белән җир казый башлаган. Минут эчендә тирән чокыр казып өлгергән. Кырмыскага карап:

— Инде мин эшләгәнне син эшләп кара,— дигән.

— Хәзер күрерсең,— дигән Кырмыска һәм дусларына ым каккан.

Кырмыскалар шунда ук эшкә керешкәннәр. Һәркайсы энә башы хәтле генә җир бөртеген кабып читкә ташлый башлаган. Ләкин кырмыскалар шулкадәр күп булганнар. Алар җир алган урын

шунда ук тирән чокырга әйләнә барган. Ә илткән җир урынында биек тау үсеп чыккан. Андый биек тауның моңа кадәр берәүнең дә күргәне булмаган. Шуннан соң безнең батыр Кырмыска болай дигән:

— Кырмыска халкы Бүредән дә, Төлкедән көчлерәк. Барлык җәнлектән көчлерәк. Шуңа күрә урманның хаким-патшасы — без.

Зур усал җәнлекләр авызларын ачканнар да катканнар. Алар бар да усаллар, ләкин куркаклар бит.

— Кырмыска халкы — урманның хаким-патшасы. Безгә ни кушсагыз, барын да үтәрбез. Ни телисез? — дип сораганнар.

Кем сораган?

Бүре сораган. Төлке, Аю сораган. Күзлекле Елан да сораган.

— Безнең хаким-патша булуыбызны аңлагансыз. Әйбәт иткәнсез. Моннан соң шәфкатьле көчсез җәнлекләрне рәнҗетәсе булмагыз. Ә үзегез җаныгыз ничек тели, шулай яшәгез,— дигән батыр Кырмыска.

Кырмыскалар башлаган эшләрен дәвам итәргә таралганнар. Алар казыган урынны күрсәгез шаккатырсыз. Төшсәң менә алмассың, очына җитәм дип юлга чыксаң, очына җитә алмассың. Ул чокырга инештән су ага-ага озын, киң елга хасил булган.

Менә шуннан соң уңган кырмыскалар урманның хаким-патшалары булып яши башлаганнар.

Люда.

?! Әсәрне кыскартып сөйләгез. Сүзегезне төп катнашучылардан башлагыз. Алар көчлеләр һәм көчсезләргә бүленәләр.

1. Әсәрдә кабатланган вакыйгалар бар. Аларны кушып сөйләсәгез, әсәр кыскара. Мәсәлән, көчле җанварларның «без патша» дип белдерүләре кабатлана. Димәк, ул вакыйгаларны бер өлеш итеп кушарга, ягъни уртак исем табарга кирәк.

Тагын нинди вакыйгалар кабатлана?

2. Автор хайваннар, җанварлар, бөҗәкләр турында язса да,— барыбер кешеләрне күз алдында тота. Куянда кешеләрнең нинди сыйфаты бар?

3. Көчле җәнлекләрдә кешеләрнең нинди сыйфаты бар?

4. Автор әкияте белән безгә ни әйтә?

Әсәрне өлешләргә бүлү.

Дәреслектәге рәсемдә кыз күп санлы курчакларын ике өлешкә генә калдырып бүлә: песиләрне бер якка, этләрне икенче якка тезә. Башкача әйтик: песигә охшаган курчакларын бер якка куя. Аларга «песиләр» дип уртак исем бирә. Песигә



охшамаган башка курчакларына «этләр» дип уртак исем бирә.

Әсәрне без дә шул кыз кебек бүләчәкбез.

«Яхшылык кылган — аш җыйган, яманлык кылган — таш җыйган» мәкален өлешләргә бүлү өчен, «ни турында, тагын ни турында?» дип, үзебезгә сорау бирәбез. Җавап. Мәкаль яхшылык һәм яманлык турында, дип ике өлешкә бүленә.

НИ ӨЧЕН?

Барысын беләм:
Кыш — чана шуар өчен,
Җәй — бәбкә куар өчен.
Яз — көймә ясар өчен,
Су — тәнне пакьләр өчен,
Ай — Җирне саклар өчен.
Тагын, тагын әллә ниләр
Әллә нәрсәләр өчен...
«Дүрт»ле белән «биш»ле алу
Әни яратсын өчен.
Белмим менә «ике»леләр
Һәм «бер»леләр ни өчен?

Разил Вәлиев.

?! **1.** Әсәрнең бер өлеше табигать күренешләре турында. Икенчесе ни турында?

2. Шигырьне дәвам итегез:

а) Кыш — кар бабай ясау өчен,

ә) Җәй — җиләккә бару өчен...

ТӘРБИЯЛЕ МАЛАЙ.

Зөфәр урамга чыкканда, күрше капка төбендә ике әби утыралар иде. Туп-туры шулар янына атлады:

— Исәнме, Хәмдия әби!

Күрешергә кулын сузгач, күрше карчыгы башта аптырап калды, соңыннан:

— Бәрәкалла! Зөфәр улым, синме бу? — дип, аның бармакларын учына кысты.

— Исәнме, Мөшәррәфә әби!

Аңа да ике кулын бирде.

— Бигрәкләр дә итагатьле бала икәнсең, улым. Олыны олы итә беләсең,— дип мактадылар әбиләр

Зөфәрне.— Әйдә, ахирәт, бу балага бәхет-тәүфыйк теләп, дога кылыйк. Аллаһы Тәгалә алдагы көнендә дә миһербанынннан ташламасын! Амин!

Аларның дога кылып бетергәннәрен Зөфәр көтеп җиткерә алмады, урамның каршы ягына ашыкты. Капкадан Гапteликъсан бабай чыгып килә иде.

— Исәнме, Гапteликъсан бабай!

— Бик исән генәме, улым!

Ике куллап күрешкән чакта, картның таягы төшеп китте. Ләкин Зөфәрнең аны алып бирерлек вакыты юк, урам буйлап, Түбән очның өч сыер савучысы җәйләүдән кайтып килә иде.

Кызганыч, Зөфәр аларның исемнәрен белми. Каршыларына чыгып, һәрберсенә:

— Исәнмесез! — дию һәм кул бирү белән чикләнде.

Өлкәннәрдән мактау сүзе ишетү күңелле икән. Зөфәр һәр мактаудан бер карыш үсеп киткәнен тойды. Савымчы апаларының кайсыдыр, кесәсеннән алып, суыра торган кәнфит тә сузды.

Төш вакыты җиткәндә, Зөфәрнең эше тыгызланып китте. Авыл кешеләре төркем-төркем өйләренә кайта башладылар. Берсе белән күрешкән арада, икенчесе шактый ерак китеп өлгерә. Йөгер аннан артыннан куып җиткәнче!

— Абый, Харрас абый, дим, исәнмесез!

— Син миңа әйтәсеңме әллә, үскәнем? Исәнме!

Бүген иртән Зөфәргә әнисе:

— Улым, итагатьле булырга өйрән, кешеләр белән исәнләшергә онытма! — дигән иде.

Әнисе кушканны үтәү Зөфәр кебек алты яшьлек зур малайга да җиңел түгел икән. Ул берәү белән дә күрешмичә калмады. Зурларның кайберсе моның өчен Зөфәрне кычкырып мактады. Икенчеләре аркасыннан сөйде. Болай гына китеп баручылар да табылды. Бары янгын сүндерүче Тимерхан абыйсы гына көлеп:



— Уф, энем, дүртенче тапкыр исәнләшәбез бит инде, бүгенгә җитеп торыр! — дип әйтеп салды.

Нур Әхмәдиев.

?! **1.** Күршедәге Хәмдия әби ни өчен башта аптырап кала?

2. Зөфәрнең сезгә ошаган һәм ошамаган сыйфатларын әйтегез.

3. «Исәнме» сүзе Зөфәр әйткәч матураямы, әллә ямьсезләнәме? Ни өчен?

4. Зөфәр тәрбияле баламы, әллә түгелме?

ТӨЛКЕ БЕЛӘН КАРГА.

Карга агач башында утыра. Томшыгында хәлвә кисәге. Хәлвәне Төлке күреп ала. «Ашыйсы иде шуны»,— дип уйлый Төлке. Ләкин Карга биектә. Ә Төлке агач башына менә алмый. Уйлый торгач, хәйләсен таба: Карганы мактарга тотына. Каурыйларының матурлыгын мактый. Күзең гүзәл, ди. Синнән дә игелекле зат юк бу дөньяда. Сине

һәркем ярата дип тә ялагайлана.

— Шулкадәр күп уңай сыйфатларыңа сандугач тавышы да өстәлсә, хәтта бөтен дөньяны нурга күмгән кояштан да матуррак булыр идең,— дип, сүзен тәмамлый Төлке.

Карганың шундый мактауга башы әйләнә. Төлкегә үзенең гүзәл тавышын ишеттерергә тели. Авызын киң итеп ачә да «Карр» дип кычкырып җибәрә. Томшыгын ачу белән, хәлвә шап итеп җиргә төшә.

Төлкегә шул гына кирәк тә. Хәлвәне ул күз ачып йомганчы кабып йота.

Китәр алдыннан, Төлке:

— Мин әйткәннәрне исеңә төшер әле, Карга. Мин синең кыяфәтеңне мактадым. Ләкин акылың турында бер сүз дә әйтмәдем,— ди.

Нәтиҗә. Ялагай мактарга керешсә белеп тор, ул синнән нидер алмакчы була.

?! **1.** Мәсәлләр гыйбрәт алу өчен языла. Катнашучыларның кайсысыннан гыйбрәт алабыз?

2. Нәтиҗәне тагын да кыскарак итеп әйтегез.

ХИКӘЯТ.

Бер сабый бала кояшлы көндә үзенең күләгәсен күрде. Аның артыннан җитмәкче булды. Ул барган саен, күләгә һаман алга китә. Баланың ачуы килде. Күләгәнең өстенә басарга теләп йөгерә башлады. Ул йөгерсә, күләгә дә йөгерә. Туктаса, күләгәсе дә туктый. Бала тәмам арыды. Кире кайтканда, артына әйләнеп караса, күләгә артыннан ияреп килә. «Һи, мин юкка йөгергәнмен икән, ул миннән үзе дә калмый икән»,— диде бала.

Каюм Насыйри.

?! **1.** Хикәятне дәвам итегез.

2. Малайга бәя бирегез.

3. Малайга ачуы килсә, кояш ни эшләр иде?

БАРЫСЫН ДА ЯРАТАМ.

Киногa барган чакта,
Әтиемне яратам.
Тәмләп-тәмләп ашаганда,
Әниемне яратам.
Ә абыем ачуланса,
Мин апамны яратам.
Дәрес хәзерләгән чакта,
Абыемны яратам.
Күрше малае кыйнаса,
Әбиемне яратам.
Әкият сөйләгән чагында,
Мин бабамны яратам.

Разил Вәлиев.

?! **1.** Бала ни өчен абыйсын дәрес хәзерләгәндә, ә әбисен үзен күрше малае кыйнаганда ярата?

2. Бала әтисен, әнисен, абыйсын, апасын, әбисен, бабасын ярата мы?

3. Әсәрнең беренче өлеше нәрсә турында? Икенче өлеше нәрсә турында?

БАКЧА.

Чәчәккә үрелүгә,
Сизде бугай уемны:
— Ө-зз-змә! — диеп, бал корты
Чагып алды кулымны.

Рәшит Бәшәр.

?! Бала өенә елап кайта. Әнисе аңа кортның ни өчен ачуы килүен аңлата. Ничек аңлата?

САКАЛЛЫ МАЭМАЙ.

Кәҗә түгел, маэмай ул...
Эре генә атлай ул...
Эре атламас иде дә,
Дәрәҗәсен саклай ул.
Хуҗага кагылсалар,
Өреп кенә ятмай ул,
Дәрәҗәсен генә түгел,
Хуҗасын да саклай ул.
Сакаллы да, акыллы да,
Менә шундый маэмай ул.

Илдар Юзеев.

?! **1.** Этнең сыйфатлары күп. Арадан иң әһәмиятле булган икесен әйтегез.

2. Этнең сакалы юк. Ләкин автор шигыренең исемен «Сакаллы маэмай» дип куйган. Ни өчен шулай иткән?

РӘСЕМ ЯСЫЙМ.

Көнбагыш чәчәге ясыйм,
Сары карандаш алдым.
Эшем бетте, исем китте:
Кояшны ясаганмын.

Равил Фәйзуллин.

?! Малайның бу хәлгә исе киткән. Ни өчен?

НИШЛӘДЕМ МИН?

Шундый оста атам мин,
Үзем дә шаккатам мин.
Читәндәге чүлмәкне
Күз йомып та ватам мин.

— Шул песнәкнең күзенә
Тидеримме, Зилә? — дим.
Зилә елый: — Нишлисең?
Тимә инде, тимә, ди.

Йөрмәсәнә арттан,— дим,—
Атам дигәч атам! — дим.
Рогатканың резинын
Бар көчемә тартам мин.

Сабы сынып аткычның
Шул чагында шарт итеп,
Маңгаема уң кулым
Бирде берне, шап итеп.

Күздән утлар күренде...
Бу Зиләсен күр инде,
Үртәп тора абзыйсын:
— Нигә тагын атмыйсың?

Хәкимҗан Халиков.

?! **1.** Шигырьне әйбәт кыз, начар малай дип, капма-каршы якларга бүлеп була. Малай кайсы ягы белән начар, Зилә кайсы ягы белән яхшы?

2. Әсәрнең беренче өлеше — малайның яманлык эшләве, ә икенче өлеше — аңа бирелгән җәза. Аңа ике төрле җәза бирелә. Нинди җәзалар?

УЕНЧЫКЛАР ОСТАСЫ МИН.

Аю да бар
Безнең өйдә,
Бүре дә бар
Безнең өйдә.
Озын колак
Куян да бар,
Керпе белән
Елан да бар.
Кошлар дисәң —
Ни телисең!
Үзем ясыйм
Бөтенесен:
Кайсын агач
Тамырыннан,
Ясаштырам
Балчыктан да,
Кәгазь яки
Мамыктан да...
Килеп керде
Бала-чага,
Берсе миннән
Керпе сорый,

Төлке сорый.
Ә мин: — Әйдә,
Алыгыз,— дим.
Энем куа:
— Барыгыз,— ди,—
Күренмәгез
Күземә! — ди.
— Бөтенесе
Үземә! — ди.
— Юк инде,— дим,—
Бусы — сиңа,
Ә болары —
Дусларыңа.
Бергә-бергә
Уйнагыз,— дим,—
Йә, ни кирәк —
Сорагыз? — дим.
Шундый инде,
Кыскасы, мин:
Уенчыклар
Остасы мин.

Хәкимҗан Халиков.

?! **1.** Катнашучылар өчәү. Аларның икесе күренеп тора — уенчыклар остасы һәм аның энесе. Өченчесен уйлап табарга кирәк.

2. «Уенчыклар ясаучы оста һәм юмарт. Ә аның энесе, киресенчә, менә мондый...»,— дип башлагыз һәм дәвам итегез.

3. Соңгы дүрт юлда малай үзен уенчыклар остасы мин, ди. Ләкин мактанмый, киресенчә, мактанган булып үзенең бик матур бер сыйфатын әйтми калдыра. Нинди сыйфатын әйтми калдыра. Ни өчен әйтми?

ЧУКМАР БЕЛӘН ТУКМАР.

Бер әбинең ике әтәче булган. Бу әтәчләрнең берсе ак, берсе кара икән. Ул аларның икесен дә бертигез ярата икән.Әтәчләр күп вакытларын сугышып үткәрәләр, сугыша башласалар, канга батып бетәләр икән.

Ак әтәчкә әби Чукмар дип исем кушкан, карасын Тукмар дип атаган.

Бердәнбер көнне бу әтәчләр шулай бик каты кычкырышканнар һәм канга батканчы сугышканнар. Әбинең моны күреп ачуы килгән. Тегеләрне бик каты орышкан. Тегеләр әби алдында бераз тынычланып торганнар, әби аларның күзләреннән югалгач, тагын сугышырга тотынганнар.

Әби килеп җитсә, Чукмар исемле ак әтәч йөгереп килеп:

— Әби, әби, кара әле, Тукмарың тукмый-тукмый башымны күгәртеп бетерде,— дип әләкли икән. Тукмар исемле кара әтәч тә энесеннән калышмый:

— Башымны кара әле, әби, Чукмарың чукый-чукый канатып бетерде,— ди икән.

Әби бер сүз дә әйтмәгән, Тукмарны култыгына кыстырган да каядыр күтәреп киткән.

Ялгыз калгач, Чукмарга бик күңелсез булган. Юньләп ашый да, эчә дә алмаган. Әбигә ул: «Тукмарны алып кайтсана, инде бер дә сугышмас идек»,— ди икән. «Ярый,— дигән әби,— алып кайтсам кайтыйм, әгәр тагын сугыша торган булсагыз, ул вакыт тотам да берегезне юк итәм,—дип куркытып куйган һәм күршедәге Тукмарны алып кайткан.

Тукмар да Чукмарны бик сагынган булган. Алар кочаклашып исәнләшкәннәр һәм киләчәктә бер дә сугышмаска сүз биргәннәр.

Абдулла Алиш.

?! Әсәрне ике өлешкә бүлегез.

ЧҮЛМӘК БАШЛЫ КӘҖӘ.

Кәҗә беркөнне
Кухняга керде.
Чүлмәк төбендә
Апара күрде.

Ашыйм, дип ашыгып
Тыкты да башын,
Кире чыгарып
Ник бер алалсын.

Нишләргә белми,
Чүлмәкне болгый:
«Харап булдым бит!
Харап булдым! — ди.—

Кайда соң ишек?
Чыгыйм,— ди,— ничек?»
Чүлмәк төбен дә
Булмый бит тишеп.
Анда да чапты,
Монда да чапты,
Көчкә-көчкә ул
Ишекне тапты.

Ишегалдында
Йөргән бар халык
Башта торды да
Карап, таң калып,

Кәҗә торганын
Күреп каршыда,
Ботларын чабып
Көлде барсы да.

Кәҗә бик яхшы
Хәйләсен тапты —
Чүлмәкне җиргә
Бәрде дә ватты.

Яктырып китте,
Дөнья ялт итте.
«Инде урлашмам»,—
Дип, ул ант итте.

Бари Рәхмәт.

?! **1.** Шигырьдә катнашучыларны әйтегез.

2. Шигырьне ике өлешкә «Кәҗә һәм халык» дип бүлеп була. Тагын ничек бүлеп була?

3. Автор безгә: «Мин ни турында яздым, әйтеп кара әле?» — ди. Сез нәрсә дип җавап бирерсез икән:

Кәҗәләр карак була, дипме?

Карак кәҗәдән халык көлә, дипме?

Кәҗәләр ахмак булалар, башларын чүлмәккә тыгалар, дипме?

Ярамаган эш эшләсәләр, хәттә кәҗәләр дә җәза алалар, дипме?

Әллә башкачамы?

ЯХШЫЛЫККА — ЯМАНЛЫК.

Бер карт, капчыгын асып, базарга киткән. Урман эченнән барганда, каршына бүре килеп чыккан.

— Артымнан атка атланган ике аучы куа килә. Ярдәм итә күр,— дип ялынган Бүре.

Бабай бүрене капчыгына салган. Бераздан аучылар да килеп җиткәннәр.

— Әй бабай, берәр бүре күрмәдеңме? — дип сораган егетләрнең берсе.

— Юк шул, улым, миңа очраучы булмады,— дигән бабай.

Аучылар киткәннәр. Капчыктан чыккач, Бүре әйткән:

— Ярар, бабай, коткардың, инде мин сине ашыйм,— дигән.

?! Әкиятнең укыган хәтлесен ике өлешкә бүлегез. Беренче өлеше бабайның яхшылыгы турында. Икенче өлешен табыгыз.

Бабай курыккан. Алай да каушамаган.

— Синеңчә булсын. Ләкин башта: «Бу дөньяда яхшылыкка — яхшылыкмы, әллә яманлыкмы»,— дип, башкалардан сорап карыйк. Яхшылыкка — яманлык дисәләр ашарсың,— дигән.

Бүре риза булган. Бара торгач, боларга Ат очраган.

— Бу дөньяда яхшылыкка — яхшылыкмы, яманлыкмы? — дип сораган карт Аттан.

— Яманлык. Мин хуҗама егерме ел хезмәт иттем. Картайгач куып чыгарды,— дигән Ат.

Бераз баргач, Сыер очраган. Сыер да, яхшылыкка — яманлык, дип җавап биргән.

?! Бу өлештәге өч вакыйга бер-берсенә охшаган. Ничек охшаган? Шул вакыйгаларны табыгыз.

Йөри торгач, боларга Төлке очраган. Бабай аңа да хәлне бәйнә-бәйнә сөйләп биргән.

— Бу дөньяда яхшылыкка — яманлык кына бар. Шуның өчен мин бу бабайны ашыйм,— дигән Бүре.

— Карт сине шушы капчыкка салып коткардымы? — дип сораган Төлке Бүредән.

— Әйе, шушы капчыкка салып коткарды,— дигән Бүре.

— Ышануы кыен, син ул капчыкка сыя алмыйсың бит,— дигән Төлке.

— Ышанмасаң, менә кереп күрсәтәм,— дигән Бүре.

— Күрсәт, барыбер сыймыйсың,— дип котырткан Төлке. Бүренең капчыкка кереп ятуы булган, бабай капчык авызын бәйләп тә куйган.

Шуннан соң Төлке әйткән бабайга:

— Йә бабай, ашлыгыңның башагын ничек коясың, күрсәт үзенә,— дигән. Бабай зур гына таяк алып капчыкны тукмый башлаган. Үзе тукмый, үзе:

— Без ашлыкның башагын менә болай коябыз, менә болай коябыз,— дип кабатлый икән.

?! **1.** Әкиятнең өзеп-өзеп укыган өлешләрен бергә кушып сөйләгез.

2. Кыскарта-кыскарта сөйләсәгез, «болай уйлаучылар» һәм «шуның киресен уйлаучылар» дип, әсәрне ике өлешкә бүлә аласыз.

3. Әкиятне ике өлешкә моңа кадәр өйрәнгәнчә дә бүлә аласыз. Уйлап карагыз әле, әсәр тагын ничек бүленә?

ГАРМУН.

(Р. Кутуйдан.)

Кичә иске гармун таптым
Үзебезнең чормадан.
«Тимә аңа,— диде әби,—
Әй, кулың тик тормаган!
Күрәсеңме, картайган ул,
Тавышы да карлыккан.
Ничек шәп биетә иде —
Сора бөтен халыктан...
Бабаңны көтте сугыштан...
Бир гармунны, бир, улым,
Син бүтәне белән уйна —
Менә синең гармуның».

Разил Вәлиев.

?! **1.** Шигырьдә катнашучыларны әйтегез.

2. Ике гармун турында сөйләгез.

3. Әсәрне ике өлешкә бүлегез.

ТҮ-ТҮ-ТҮ-ТҮТ.

Баганалар
Тезелешеп,
Артка чаба.
Без барабыз
Җан-фәрманга
Алга таба.
Түү-ту-ту-түт!

Кино кебек
Карыйм яңа
Якларны мин.
Выжылдатып
Узып китәм
Атларны мин!
Ту-ту-ту-түт!

Яратам мин
Тиз йөрүне
Тигез юлда!
Җил бик җитез,
Тик калыша
Бездән ул да.
Ту-ту-ту-түт!

...Әткәй әйтә:
— Руль тотарга
Сиңа иртә.
Машинаны
Әлегә ул
Үзе йөртә.
Ту-ту-ту-түт!

Шәүкәт Галиев.

?! **1.** Шигырь тиз йөрүче машина турында. Тагын ни турында?

2. Шуларның кайсы үзәктә: баганалармы, атмы, җилме? Ни өчен?

3. Баганалар ни өчен артка чабалар?

Өлешләр арасындагы бәйләнеш.

Бу дөньяда һәрнәрсә бер-берсе белән бәйләнештә яши. Кояш белән җир (кояш җирне җылыта), кешеләр кешеләр белән (дуслашалар, бергәләп эшлиләр), җил агач белән (агачны селкетә) бәйләнешкә керә. Сез мәктәп белән

(мәктәптә белем аласыз), китап белән (өйгә кайткач, рәхәтләнеп китап укыйсыз) бәйләнешкә керәсез.

Дәвам итегез, тагын нәрсәләр белән бәйләнешкә керергә мөмкин.

?! **1.** Болыт җир белән нинди бәйләнешкә керә?

2. Ат ниләр белән бәйләнешкә керә?

3. «4»ле алса, Ибрайның «4»лесе шунда ук шатлыгы белән бәйләнешкә керә, ә Сәҗидә «4»лесе борчылу белән бәйләнешкә керә. Ни өчен?

Тормышта шулай бер-берсен якын иткәч, предметлар, әдәби әсәрдә дә бәйләнешкә керү өчен, үзләренә иш эзлиләр. Безгә яхшы таныш бәйләнешләрне искә төшерик: әсәр укыганда, автор белән бәйләнешкә керәбез. Әсәрдә катнашучылар үзара бәйләнешкә керәләр. Безгә иң кирәкле бәйләнеш әсәр эчендәгесе.

Әсәрен язганда автор иң башта әнә шундый бәйләнешне эзли: ике өлеш арасына җепләр суза. Болар охшаганнар, ди. Кара әле, болар бит тышкы яктан гына охшаганнар. Чынлыкта капма-каршы нәрсәләр, ди, ул җепләр. Алар әле тагын әллә ниләр турында сөйләячәкләр, ләкин ул кадәресе белән алдагы дәресләрдә танышырбыз.

Искә төшерик. Ике предмет һәм алар арасындагы бәйләнешкә **төзелеш** диләр.

Тамчы, тама-тама, таш тишәр мәкаленең төзелеше мондый: бер якта — тамчы, икенче якта — таш. Тамчының ташка өзлексез тамып торуы алар арасында бәйләнеш тудыра. Менә шул тамып тору бәйләнешендә автор сүзе ята. Ул безгә: тырышыгыз, тырышсагыз, авырлыкларны җиңәрсез, күрдегезме, хәтта зәгыйфь кенә тамчы да нинди каты ташны тишә, ди.

?! **1.** Чебен дулап тәрәзә вата алмас; Калган эшкә кар явар; Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын; Бауның озыны, сүзнең кыскасы яхшы; Әкрен барсаң, ерак китәрсең; Эшләгәнең кеше өчен булса, өйрәнгәнең үзең өчен мәкальләренең бәйләнешкә кергән ике ягын табыгыз.

2. Хәтерегезне үстерегез: мәкальләрне бер кат укып чыккач, ничәсен хәтердә калдырдыгыз? Дәфтәрегезгә язып куегыз. Ике тапкыр укыганнан соң, ничәсе хәтерегездә калды? Аларын да дәфтәрегезгә языгыз.

Бәйләнешнең иң якын дуслары — **каршылык**, **охшашлык** һәм **кушылу**. Кайсы гына әсәрне укыма, каршылык, охшашлык, кушылу белән очрашасың. Очрашып кына калсаң бер хәл иде әле, алар синең колагыңа: «Без монда кунак түгел, тулы хокуклы катнашучылар. Без әдәби әсәрнең төткалары, без аны төзибез. Безнең белән дус булсаң, без сиңа авторның уен, хисен табарга өйрәтербез,

диләр. Син безне яратсаң, без сине яратырбыз»,— дип тә өстиләр.

Менә шундый бик игелекле өч дус белән без дә дуслашыйк.

Каршылык.

Каршылык һәрнәрсәне каршы якларга бүлә. Ул хәтта сүзләр эченә кереп, аларны да каршы якларга аерып ташлый.

Күпме йөрсәк тә без
Җәен,
Каптыра алмадык
Җәен,—

дип, шагыйрь Шәүкәт Галиев «Җәен» сүзен икегә бүлә дә шигырь иҗат итә.

Ике дус кыз бер-берсенә үпкәләп сөйләшми йөрсәләр, аларның «борчаклары пешми» диләр.

— Борчакның монда бер катнашы да юк. Аларның арасын мин боздым,— ди каршылык. Кайберәүләр турында «алар эт белән мәче кебек яшиләр» диләр.

Әсәрдәге каршылыкны өйрәнү нигә кирәк?

Каршылык ялгыз яши алмый. «Менә мин!» дип үзен күрсәтү өчен, аңа ике өлеш эзләп табарга кирәк. Ә ул өлешләрне табарга автор ярдәм итә. Димәк, каршылыкны тапсак, әсәрне ике өлешкә бүлә алабыз.

Каршылык безнең белән качышлы уйнарга ярата. Әсәрнең берәр өлеше эченә кереп яшеренә

дә, табыгыз, тапсагыз, бу өлешне икегә бүлә аласыз, ди. Шундый шаян вакытында аны без әсәр эченнән үзебез эзләп табарга тиеш булабыз.

Мәкальләрдәге каршылык.

Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын, ди мәкаль. Мәкаль төзелешенең бер ягында акча, икенче ягында дус тора. Акчаны аны туңдырмага да алыштырып була. Дусны шулай алыштырып карагыз! Дуслык акчадан кыйммәтрәк, ди автор, акча белән дусларны каршылыкка китерә.

?! Түбәндәге мәкальләрне ике өлешкә бүлегез. Өлешләре каршылыкта торганнарын күрсәтегез.

- Йомшак җәеп, катыга утырта.
- Әкрен барган кеше — куян артыннан җиткән.
- Дөя дә бүләк, энә дә бүләк.
- Кешегә баз казыма — үзең төшәрсең.
- Еракка куйсаң, якыннан алырсың.
- Белгәнеңне сөйләмә, ни сөйләгәнеңне бел.

Табышмаклардагы каршылык.

Бер кисмәктә мең егет, ди табышмак авторы. Кыяр тышын кисмәккә, ә эчендәге орлыкларын кешегә охшата. Каршылык юк җирдән каршылык тудыра. Шундый кисмәк буламыни? Мең егеткә анда ни калган дибез без. Ә бит уйлап карасаң, каршылык юк икән, кисмәккә бер генә егет тә

кермәгән. Табышмак җавабын табыгыз, ди безгә автор. Әһә, төшләрен эченә тутырган кыяр икән бит ул кисмәк. Җавапны табу өчен, әнә шул каршылыктан котылырга тиеш булабыз.

?! Түбәндәге табышмакларның кайсысында каршылык бар?

- Кыйнамый, сукмый, үзе елата. *(Кычыткан.)*
- Суда коенып алды — өсте коры калды. *(Каз.)*
- Ак күл эчендә сары күл. *(Йомырка.)*
- Аягы бар, кулы юк,
  Аркасы бар, түше юк. *(Урындык.)*
- Мич тулы пәрәмәч,
  Уртасында бер калач. *(Йолдызлар, ай.)*

Мәзәкләрдәге каршылык.

ИСКЕ КИТАП — ЯҢА КИТАП.

Укытучы:

— Укучылар, бу әсәр иске дәреслекләрдә юк, яңаларында гына бар. Шуңа күрә мин сөйләгәнне игътибар белән тыңлагыз.

Шулвакыт Ринатның китап актарганын күреп:

— Эзләмә, иске китапларда юк,— ди укытучы, сүзен кабатлап.

— Нишләп иске булсын ул, яңасы шундый булды аның,— ди Ринат.

?! **1.** Ринатның китабы искеме, яңамы?

2. Түбәндәге мәзәкләрне өлешләргә бүлегез, алар арасындагы каршылыкларны табыгыз.

АЗ АЛМА, КҮП АЛМА.

Ирек йокысыннан уянды да әбисенә төшен сөйләде:

— Әби, мин бүген төш күрдем, имеш, син миңа кып-кызыл зур алма бирдең.

— Әйбәт укы, улым,— дигән әбисе.— Әйбәт укысаң, төшеңдә тагын өч кып-кызыл алма бирермен.

БАР ДА, ЮК ТА.

Бай, көтүчесен чакырып, сарыкларын санарга кушкан.

Икенче көнне көтүлеккә килеп:

— Йә, ничәү булды? — дип сораган.

Өч йөз кырык алтысын санадым. Берсен санап булмады. Ул гел әрле-бирле чабып йөрде,— дип зарланган көтүче.

НИЧӘ КОШ?

Кунак булып килгән кардәшләре, Кавига бер төргәк күрсәтеп әйтте:

— Бу төргәктә нәкъ егерме конфет. Әгәр шул конфет саны кадәр кош исемнәрен атый алсаң, төргәк синеке,— дигән.

— Чыпчык, карга, саескан, песнәк, тургай, күгәрчен, каз, үрдәк, әтәч белән тавык, аларның ун чебешләре...

?! Кардәш абыйсы Кавига бүләген биргәнме?

Мәсәлләрдәге каршылык.

ИКЕ АТ.

Ике Ат ике йөк тартып бара. Алдагы Ат әйбәт тарта, ә арттагысы еш туктый. Йөкнең бер өлешен арттагы арбадан алып, алдагы арбага төйиләр.

— Интек, әйдә, тиргә бат. Ныграк тырышкан саен, күбрәк интегерсең,— ди арттагы Ат алдагы Атка.

Кайтып җиткәч, атлар хуҗасы әйтә:

— Арбаны Атның берсе генә дә тарта ала икән. Ике Ат ашатканчы, азыкны берсенә күбрәк бирермен. Берсен суярга кирәк булыр,— ди.

Шулай эшли дә.

Лев Толстой.

?! **1.** Катнашучыларны табыгыз.

2. Атларның сыйфатларын әйтегез.

3. Әсәрне ике өлешкә бүлегез. Автор безгә нәрсә дип әйтергә тели? Җавапны түбәндәге мәкальләрнең берсеннән сайлап алыгыз.

- Начар кешегә таянганчы, суга таян.
- Яманлык беркайчан да яхшылык белән тәмамланмый.
- Ат тартмаса, арба бармас.
- Ат яхшы булса, чыбыркы кирәкмәс.

КЕРПЕ БЕЛӘН КУЯН.

— Килмәгән җирең юк синең, Керпе. Тик менә аякларың чалыш,— ди Куян Керпегә. Керпенең бу сүзләргә ачуы килә:

— Минем чалыш аяклар синең туры аякларыңнан тизрәк чаба. Ышанмасаң чабышыйк. Әзерләнә тор, мин хәзер өйгә генә кайтып киләм,— ди. Өендә хатынына әйтә:

— Куян белән бәхәсләштем. Йөгерешәбез. Мин әйткәннәрне төгәл үтәсәң узам мин аны,— ди.

Сөргән җиргә килеп җитәләр. Керпе хатынына әйтә:

— Син буразнаның менә бу башына яшерен. Без теге яктан чабыша башлыйбыз. Куян чабып килгәч, качкан җиреңнән чык та: ә мин күптән монда инде! дип кычкыр,— дигән.

Керпе белән Куян аргы яктан чаба башлыйлар. Куян бирге якка килеп җиткәч, анда Керпе утырганын күреп шакката.

— Әйдә, теге якка таба да чабыйк,— ди Куян һәм җан-фәрманга кире якка элдерә. Барып җитсә — анда Керпе көтеп утыра.

— Шундый нык чаптым, кай арада узган соң ул мине? — дип аптырый Куян. Әйдә, тагын чабышыйк, ди. Керпе шунда ук риза була.

Әле бер якка, әле икенче якка чаба-чаба тәмам хәлдән тая Куян. Шуннан соң оттыруын таный. Башка бервакытта да бәхәсләшмәм, дип сүз бирә.

Лев Толстой.

?! **1.** Куянның ямьсез сыйфаты да, матур сыйфаты да бар. Шул сыйфатларын әйтегез.

2. Керпенең Куяннан өстен ягы да, калышкан ягы да бар. Шул сыйфатларын әйтегез. Кайсы яхшырак: Куянмы, Керпеме?

Мәсәлнең каршылыгын табыйк.

Бик әкрен чаба торган Керпе Куянны уза. Бик тиз йөгерүче Куян Керпене дә уза алмый. Башкача әйтик: мәсәлдә акыл белән көч ярыша. Акыл җиңеп чыга. Мактанчык Куян җәза ала.

Әкиятләрдәге каршылык.

ӨЧ КЫЗ.

Борын-борын заманда булган икән, ди, бер хатын. Аның булган, ди, өч кызы. Бу хатын, кызларымның өсте бөтен, тамаклары тук булсын, ди-ди, көне-төне эшләгән, ди.

Менә кызлар буйга да җиткәннәр. Берсе артыннан берсе кияүгә чыгып китеп тә барганнар.

Бер ел үткән, ике ел, өч ел үткән. Шулай матур гына яшәгәндә, әнкәләре авырып киткән. Күрше урманда Тиен дусты бар икән, шуны дәшеп әйткән:

— Тиен дустым, барсана, кызларыма әйтсәнә, хәлемне белергә килсеннәрче,— дигән.

Тиен шунда ук чыгып чапкан. Тиен барып тәрәзә какканда, олы кыз җиз ләгән тазартып тора икән.

— Һай-й,— дип әйткән, ди, олы кыз,— бик барыр идем дә бит, менә шушы ләгәннәрне тазартып бетерәсем бар шул,— дигән, ди.

Тиен моңар бик ачуланган да әйткән:

— Алайса, син шушы ләгәннәреңнән мәңгегә аерылма! — дигән.

Тиеннең шулай дип әйтүе булган, олы кыз егылган да шунда ук бакага әверелгән.

Тиен уртанчы кызга чыгып чапкан. Уртанчы кыз киндер суга икән. Тиенгә әйткән:

— Һай-й,— дигән,— әнием янына хәзер үк чыгып йөгерер идем дә бит, киндер сугып бетерәсем бар иде шул,— дигән.

Тиен бик ачуланган да әйткән:

— Алайса, син гомер буе киндер сугып кына тор! — дигән.

Уртанчы кыз шунда ук үрмәкүчкә әверелгән.

Тиен тәрәзәсен какканда, кече кызның камыр баскан чагы икән. Ул бер сүз дә әйтмәгән.

Камырлы кулларын да сөртеп тормаган. Чыккан да әнисе янына чапкан.

Тиен кече кызга әйткән:

— И сөекле бала,— дигән,— гомер буе игелек күр. Кешеләрне бәхетле ит. Аларга юаныч бул. Кешеләр дә сине яратырлар,— дигән.

Кече кыз, чыннан да, бик рәхәт гомер кичергән, халык аны бик яраткан, ди.

?! **1.** Әкиятне кыскарта-кыскарта сөйләгез. Катнашучыларны әйтегез.

2. Әкиятне өч өлешкә бүлегез. Аларга исем уйлап табыгыз.

3. Охшаган өлешләрне кушып, әсәрне ике генә өлешкә калдырыгыз.

4. Кушылган өлеш белән икенче өлеш арасындагы каршылыкны әйтеп күрсәтегез.

5. Бакага әйләнгән олы кыз вакыйгасын «Яманлыкка җәза бирелде» дип кыскартабыз. Калган ике вакыйганы кыскартыгыз.

КАРБЫЗ ТӨШЛӘРЕ.

Кайчандыр бер ярлы агай яшәгән. Аның җире бик аз булган. Ачтан үлмәс өчен, ул ашъяулык хәтле генә җирендә көн-төн эшләгән.

Беркөнне күктә ап-ак Челән очканын күргән. Сөрелгән җиргә җиткәч, Челән кычкырып җибәргән дә егылып төшкән. Мескенкәйнең канаты сынган

икән. Агай аны өенә алып кайта. Дәвалый. Ашата, эчертә. Канаты төзәлгәч, Челән очып китә.

Яз җитә. Агай җирен сөреп чәчәргә җыена. Көтмәгәндә Челән очып килә дә өч карбыз төше ташлап китә.

Агай аларны утырта. Берничә көннән карбыз тишелеп чыга. Чәчәк ата. Агай карбыз чәчәгенең зурлыгына сокланып туя алмый.

Вакытында су сибеп, астындагы чүпләрне утый торгач, карбыз өлгерә. Агай аларның өчесен өзә дә өенә алып кайта.

— Мондый зур карбызларны үзем генә ашау дөрес булмас! — ди агай һәм туганнарын, дусларын кунакка чакыра.

Икегә ярып җибәрсәләр шаккаталар — карбызның эче тулы төш, ә төшләре алтын, ди! Агай алтын төшләрне, чүпләп, кунакларына өләшә.

Өч төптән ун карбыз үсә. Агай аларны ярып алтыннарын җыя. Шуннан соң нужа күрми генә тормыш итә башлый.

Күршесендә бер бай яши икән.

— Син ничек кинәт кенә баеп киттең? — дип сорый бай.

Агай Челән тотуын һәм аның бүләге турында сөйләп бирә.

Бай шунда ук ак Челәнне эзләргә чыгып китә.

Ак Челән кырда чүпләнеп йөри икән. Бай мыштым гына килә дә аягына таяк ыргыта. Өенә алып кайтып дәвалый. Терелгәч очыра.



Яз көне Челән байга да өч төш ташлап китә.

Бай аларны кабалана-кабалана утырта. Төшләр тишелеп чыга. Чәчәк ата. Карбызлары да өлгерә. Күршесенеке кебек зур карбызлар.

Бай да кунакка дусларын, туганнарын чакыра. Пычак тиюгә карбыз икегә ярылып китә. Эченнән бер оя усал төклетура очып чыга. Аларның берсеберсе чикләвек хәтле була. Менә төклетуралар байны һәм аның кунакларын чагарга керешәләр. Кунакларның күз төпләре, иреннәре шешеп чыга, бар да, байны каргый-каргый, өйләренә чабалар.

?! **1.** Әкиятне ике өлешкә бүлегез. Икесенә дә исем бирегез.

2. Икенче өлеше беренчесенең капма-каршысы булуын исбат итегез.

ЧҮПКӘ — АЛМА.

Берәүнең бакчасы белән өе булган. Бакчасында алма, өендә улы үскән. Улына егерме яшь тулгач, өйләнергә вакыт җиткән. «Улым акыллы, эшчән. Аңа үзе кебек эшчән кыз табасы иде»,— дип уйлаган әтисе. Уйлана торгач уйлап тапкан. Арбасына алма төягән дә авылдан авылга кереп йөри башлаган. Бер җирдә атын туктаткан да:

— Алма сатам! Алма кемгә кирәк! Алманы идән чүбенә алыштырам! — дип кычкырган.

— Алмасын чүпкә алмаша. Бу карт акылдан язгандыр! — дип, кызлар көлә-көлә өйләренә чапканнар. Өйләрендә, ярыша-ярыша, идән себерергә тотынганнар. Себерә торгач, тау хәтле чүп җыялар. Капчык белән дә, чиләккә тутырып та, алъяпкыч итәгенә салып та ташыйлар.

Картка чүбен китереп бушаткан да беренчесе:

— Ел буена тапталып ята иде, ярый әле бу ахмак карт килеп чыкты. Барысын да алмасына алмаштырам! — дип мактанган.

— Чиләктәге чүпкә карап, аз дия күрмәгез. Хәзер тагын шулхәтле алып киләм. Безнең өйдә чүпнең чуты юк! — дигән икенчесе.

— Ә бездәге чүпне ел буена җыйсаң да җыеп бетерерлек түгел. Аннан-моннан гына себергәч тә бер капчык булды әнә. Бала-чага туйганчы алма ашасын әле,— дип көлгән өченче кыз.

Ә карт мыек астыннан гына елмаеп, чүп ташучыларны мактый да алма өләшә, мактый да алма өләшә, ди. Ул елмая, кызлар көләләр. Бар да шат, бар да канәгать.

Күп тә үтми, картның арбасы чүп белән тулган. Алмасы да бер-ике бөртек кенә калган. Китәргә дип җыенгач кына, арба янына яшь чибәр бер кыз килеп баскан. Кулъяулыгына төргән чүбен күреп карт:

— Чүбең бик аз бит, чибәр кыз, учка сыярлык чүпкә бер генә алма тия,— дигән.

— Чүп кызганыч түгел. Йөге белән алып килер идем дә бит, юк. Бездә чүп юк шул. Монысын да күршеләр генә бирделәр,— дигән кыз.

Карт бу сүзләргә бик шатланган. Өендә бөртек тә чүбе булмагач, эшчән, уңган кыз икән. Миңа шундый килен кирәк тә,— дигән.

Карт чибәр кызны арбасына утырткан да авылына алып кайткан. Кайтып җитү белән, туй ясаган. Шушы көнгә хәтле киленен мактап туя алмый, диләр.

?! **1.** Әсәрдә катнашучылар күп. Ләкин төп катнашучылар өчәү генә. Аларның кемнәр булуын дәфтәрегезгә языгыз.

2. Катнашучыларның картка, картның катнашучыларга бәясен (кызлар белән карт арасындагы бәйләнешне) әйтегез.

3. Хәзер әсәр ике капма-каршы якка җиңел бүленә: беренче өлештә чүп ташучылар оталар, икенче өлештә шул ук чүп ташучылар оттыралар. Ничек оталар? Ничек оттыралар?

ГӨЛЧӘЧӘК.

Борын-борын заманда зур карурман эчендә бер Убырлы карчык торган, ди. Аның бер улы белән Гөлчәчәк исемле килене булган, ди. Карчык бик явыз икән, ди. Карчыкның улы, анасының явызлыгына түзә алмыйча, дөнья гизәргә, бәхет эзләргә чыгып киткән.

Гөлчәчәк әниләрен бик сагына икән, тик аны каенанасы — Убырлы карчык — бер җиргә дә чыгармый икән. Үзе төннәрен яхшы кешеләрне аздырырга, батыр кешеләрне юлдан яздырырга чыгып киткәндә дә, киленен өйдә бикләп калдыра икән, ди.

Бер төнне Убырлы карчык ишеккә йозак салырга оныткан, ди. Көлгә салган күмәчләрен дә калдырып киткән, ди.

Ишекнең ачык калуын белү белән, Гөлчәчәк куенына төче күмәч кыстырган да, ди, әниләренә кунакка чыгып киткән, ди.

Төн киткән, көн киткән, бара торгач, байтак җир киткән. Ул арада Убырлы карчык кире әйләнеп

кайткан да килене артыннан куа чыккан. Соры бүре төсенә кергән дә, ди, җирне исни-исни чабып киткән, ди.Чаба торгач, киленен куып җиткән, ди. Гөлчәчәкнең каршысына төшкән дә, ди, калын тавыш белән улап җибәргән, ди.

Көлтә-көлтә койрыгым
Болгый-болгый улаем.
Күмәчләремне бирмәсәң,
Калҗа-калҗа тураем.

Гөлчәчәк бик курыккан, күмәч биреп кенә котылыр иде дә, ул вакытта инде аның күмәче калмаган. Ары каранган, ди, бире каранган, ди, якында гына куыш эчле зур бер карама күргән, ди. Шул карамага ялына башлаган, ди.

Әйләнмәле карама,
Бәйләнмәле карама,
Соры бүре куып җитте,
Яшерсәнә, карама,
Яшерсәнә, карама.

Әйләнмәле карама Гөлчәчәкне кызганган, ди, кечкенә куышының ишеген ачып җибәргән, ди. Гөлчәчәк куышка кергән дә качкан, ди.

Соры бүре карама төбен тырный-тырный улаган да, ди, Гөлчәчәкне чыгара алмагач, өенә кайтып киткән, ди.

?! Гөлчәчәк белән Убырлы карчык арасында каршылык арттымы, кимедеме?

Ул арада таң аткан, кояш чыккан. Гөлчәчәк, карамага рәхмәт әйтеп, тагын үз юлына чыгып киткән. Бара торгач, кич булган. Соры бүре тагын куып җиткән. Гөлчәчәкнең алдына төшеп: «Күмәчләремне бирмәсәң, калҗа-калҗа тураем»,— дип, тагын улап җибәргән, ди.

Гөлчәчәк бик курыккан, ди. Ары караган да, бире караган, ди. Түгәрәк аланда бер бик матур күл бар икән, ди. Гөлчәчәк шул күлгә ялына башлаган:

Түгәрәк алан, көмеш күл,
Көмеш күлнең суы мул...

?! Җырны тәмамлагыз.

Көмеш күл Гөлчәчәкне бик кызганган, ди, тирән суын айкалдырып, дулкыннарын чайкалдырып, Гөлчәчәк басып торган җирне тирән су белән урап алган.

Соры бүре...

?! Дәвам итегез. Бүре ни эшләгән?

Ул арада таң аткан, кояш чыккан. Гөлчәчәк, көмеш күлгә рәхмәт әйтеп, тагын үз юлына чыгып киткән.

Барган, ди, барган, ди, иртә киткән, кич киткән, урманның кырыена ук чыгып җиткән. Инде әниләренең өй түбәләре дә күренә башлаган, ди. Тик шул урында Соры бүре тагын куып җиткән дә, бу юлы бигрәк тә каты ачуланып, ярсый-ярсый улаган, ди...

?! Бүре ничек дип җырлаган?

Гөлчәчәк бик курыккан. Ары каранган, бире каранган да басу кырыенда үсеп утырган кушкаенга менеп киткән, ди.

«Инде монда кайтып җиткәч тә, әниләрне күрми үләрмен микәнни соң?» — дип әйтеп, бик

борчылып елап утыра икән, шунда кушкаен башына бер сыерчык килеп кунган, ди. Гөлчәчәк сыерчыкка ялына башлаган:

Ала муен сыерчык,
Кола муен сыерчык,
Чәч бөртегем — әманәтем[1],
Илтеп бирче, сыерчык,
Илтеп бирче, сыерчык,
Илтеп бирче, сыерчык.

Гөлчәчәк сыерчыкка бер-ике чәч бөртеген өзеп биргән. Сыерчык, аны алып, Гөлчәчәкләрнең әниләренә очып киткән дә, ди, чәч бөртеген аларның капкаларына элеп куйган, ди.

?! **1.** Әкияттәге вакыйгаларны баштан ук сөйләп чыгыгыз.

2. Гөлчәчәккә ярдәм итүчеләрнең төп сыйфатлары нинди?

Гөлчәчәкнең абыйсы капка төбенә чыккан икән, чәч бөртекләрен күргән. «Әһә, кара юргам[2] кашынып торганда ял бөртекләре калган икән»,— дип әйткән, чәч бөртеген, алып кереп, думбрага кыл итеп тарткан, ди.

---

[1] Әманәт — бик кирәкле йомыш.

[2] Юргам — атым.

Гөлчәчәкнең җиңгәсе думбраны аяк тибеп бии-бии уйный башлаган икән, думбра кылы Гөлчәчәк булып җырлап җибәргән:

Бии-бии уйнама,
Билгенәем авырта,
Тибә-тибә уйнама,
Түбәләрем авырта...

Моңар җиңгәсенең исе киткән:

— Әбәү, бу думбрага ни булган? — дип әйтеп, думбраны иренә биргән. Ире чиртеп-чиртеп уйный башлаган икән, думбра тагын җырларга тотынган:

Басма-басма, абыем,
Башкынаем авырта,
Чиртмә-чиртмә, абыем,
Чәчкенәем авырта.
Урман буе кушкаен,
Кушкаенда сеңлең бар.
Кушкаенның төбендә
Каенанам — Убыр бар.
Думбраңны куй, абый,
Кушкаенга кил, абый.

Шуннан соң абыйсы: «Карасана, Гөлчәчәк сеңлем харап була язган бит»,— дип, чукмарын алган да, ди, атына атланып, урман буена чапкан, ди. Ул барып җиткәндә, Соры бүре кушкаенның

тамырларын актарып бетерә язган. Кушкаен менә авам, менә авам, дип кенә торадыр иде, ди.

Гөлчәчәкнең абыйсы Соры бүрене бәреп үтергән дә, ди, Гөлчәчәкне өйләренә алып кайткан, ди.

Шуннан бирле Гөлчәчәк бик әйбәт гомер итә башлаган, ди.

Бүген барып, кичә кайттым, мин дә булдым аларда. Сый-хөрмәт бик дан булды. Тик авызга эләкмәде, мыек кына чыланды.

?! Гөлчәчәк белән Убырлы карчык арасындагы каршылык бетте. Әкиятләрдә һәрвакыт яманлыкны яхшылык җиңә. Монда да шулай булды. Убырлы карчыкның яманлыгы нидән гыйбарәт?

Әсәрләрдәге каршылык.

ИКЕ ТӨРЛЕ ТӘҮФИКЪ.

Мәктәптә безгә еш кына
Күрсәтәләр Тәүфикъны
Һәм мактыйлар:
— Ул тәүфикълы,
Бер дә бозмый тәртипне.

Кызлар белән дә тату бит,
Мөгамәлә матур бик —
Ялгыш кына кагылса да:
Кичер мине, гафу ит...

Директор да күргән икән,
Үрнәк итеп китерде.
Кайсыннан үрнәк алыйк соң
Тәүфикъ бит ике төрле?!

Берсе аның дәрес тыңлый,
Тыныч кына утырып.
Икенчесе астан гына
Чеметә борып-борып.

Берсе «Рәхим итегез!»не
Сүз аралаш кыстыра,
Икенчесе, тел күрсәтеп,
Аяк тибеп кычкыра.

Тәртипле дип әйтсеннәр дип,
Шулай итенгән була —
Юри аякка баса да
Гафу үтенгән була...

Бер Тәүфикъта ике Тәүфикъ,
Шулай яши ул һаман;
Тыштан күренгәне яхшы,
Астыртыны бик яман.

Шәукәт Галиев.

?! «Тәүфикъ» әдәплелек дигән сүз. Малай әдәпле дә, әдәпсез дә. Мин аны әдәпсез, дияр идем. Килешмәсәгез, исбат итегез.

МИЛӘҮШӘ НИЧЕК ЗУР БУЛДЫ?

Миләүшәнең зур буласы килде. Бик-бик зур буласы килде. Тиз үсеп китим дип, әллә ниләр эшләп карады. Әнисенең туфлиен киеп йөрде, әбисенең алъяпкычын япты. Чәчен Кәүсәрия апасыныкы кебек итеп үрде... Муенсасын үз муенына үлчәп карады, әтисенең сәгатен тагып карады — үсмәде. Кеше генә көлдерде.

Көннәрнең берендә башына бик матур уй килде: «Тик йөргәнче идән себеримме әллә?» — диде. Уйлап кына калмады, идәнне себереп тә чыгарды. Шундый әйбәт итеп себерде, хәтта әнисе дә шаккатты.

Миләүшә савыт-сабаны да юып, коп-коры итеп сөрткәч, әнисе генә түгел, әтисе дә шатланды. Бөтен гаилә ашарга утыргач, Миләүшәгә карап болай диде...

Евгений Пермяктан.

?! **1.** Әтисе кызына нәрсә дигән?

2. Шуннан соң Миләүшә ни уйлаган?

3. Миләүшә әле кечкенә, ләкин үзен зур итеп хис итә. Шул каршылыкны аңлатыгыз. Кыз нигә зур, нигә кечкенә?

4. Әбиегез идән себергәндә, сез карап торасыз, дип күз алдына китерик. Бик карт бит инде безнең әби, үзе чүп җыя. Чүбен урамга чыгарып түгә, дип, сез аны бик кызганасыз, ди. Сез бу вакытта зур да, кечкенә дә кебек. Зурмы, кечкенәме?

ПЕСИ БАЛАСЫ ҺӘМ БУА ЭЧЕНДӘ УТЫРУЧЫ «УЛ».

Беркөнне баласына Песи балыкка барырга кушкан. Бүген ай зур һәм якты булачак. Балыкны ай яктысында тоту җайлы, дигән. Юлын да өйрәткән. Буага җиткәнче туп-туры бар да бар. Буа аркылы юан агач ятар. Шул агач аша аргы якка чык. Балыкның оясы шунда, дигән.

Төн җитеп ай калыккач, Песи баласы юлга чыккан. Урманга берүзе кереп киткән. Гомерендә беренче мәртәбә япа-ялгыз кергән.

Менә нинди батыр булган безнең Песи баласы! Башта әкрен генә барган.

Аннары сикерә-сикерә киткән. Урманның иң куе, иң кара урынына җиткәч, аңа Аю очраган.

Әнисеннән башка берүзе йөргән Песине күреп, Аю гаҗәпләгән.

— Төн уртасында берүзең кая барасың? — дип сораган.

— Буаның аргы ягына чыгам. Төшке ашка балык тотып кайтам,—дип җавап биргән Песи баласы.

Әнә нинди горур сөйләшкән Аю хәтле Аю белән Песи баласы.

— Курыкмыйсыңмы соң? Миндәге көч юк бит синдә,— дигән Аю.

— Бер дә курыкмыйм,— дип җавап биргән Песи баласы.

Бәләкәй генә булса да, искиткеч батыр булган шул ул.

Песи баласы юлын дәвам иткән. Башта әкрен генә барган. Аннары сикерә-сикерә киткән.

Бара торгач, киң яланга килеп чыккан. Ә анда Төлке утыра икән. Төлке дә төн уртасында ялгыз Песи баласын күреп гаҗәпләнгән.

— Төнлә үзең генә кая барасың? — дип сораган.

— Буаның аръягына ашыгам. Төшке ашка балык тотып кайтам,— дип җавап биргән Песи баласы.

— Курыкмыйсыңмы соң? Синдә минекедәй хәйлә юк бит? — дип сораган Төлке.

— Бер дә курыкмыйм,— дип җавап биргән Песи баласы һәм юлын дәвам иткән.

Буага җитәрәк Куян очраган.

— Болай берүзең кая китеп барасың? — дип сораган Куян да.

— Буага балык тотарга барам,— дип җавап биргән Песи баласы.

— Чынлапмы? Ә син аңардан курыкмыйсыңмы? — дип сораган Куян.

— Кемнән куркыйм, ди, мин?

— Буа төбендә утыручыдан. Мин аңардан куркам,— дигән Куян.

— Ә мин бер дә курыкмыйм,— дигән Песи баласы һәм алга таба атлаган.

Бара торгач, әнисе әйткән басмага килеп җиткән. Мин шушы агач аша теге ярга чыгарга

тиеш. Балыкның оясы шунда, дигән Песи баласы. Бүрәнәгә менеп баскан. Буа аркылы чыга да башлаган.

Батыр булган ул. Тик нигә генә Куянны очратты икән? Песи баласы су төбендә утыручы берәү турында уйламаска тырышкан. Ләкин булдыра алмаган. Агачның кыл уртасында туктаган да буа төбенә күз салган.

Анда, чыннан да, кемдер утыра икән!

Куян әйткән «ул» ай яктысында Песи баласына туп-туры карап тора икән. Песи баласы куркуын аз гына да сиздермәгән. Киресенчә, аны үртәп, авызын кыйшайткан.

Теге дә, чыраен үзгәртеп, авызын кыйшайткан.

Дөньяда шундый ямьсез чырай булса да булыр икән!

Песи баласы күз ачып йомган арада борылган да җан-фәрманга чабарга тотынган. Шундый тиз чапкан — Куян белән Төлкене үтеп китүен сизми дә калган. Аюны очратканчы туктамаган.

— Ни булды? Ник чабасың? — дип сораган Аю.

— Буа төбендә галәмәт зур нәрсә утыра. Мин аны үтәргә куркам! — дигән Песи баласы.

— Әйдә, бергә барыйк. Куып җибәрәм мин аны,— дип, ярдәм кулы сузган Аю.

— Юк, юк, мәшәкатьләнмәгез,— дигән Песи баласы.

— Алайса, кулыңа таш ал. Ташыңны күргәч куркыр да качар,— дип киңәш биргән Аю.

Песи баласының өйгә балык алып кайтасы килгән. Шуңа күрә таш алган да басма уртасына килеп баскан. Теге һаман төптә утыра икән. Песи баласы ташын күтәргән. Теге дә шунда ук таш күтәреп кизәнгән.

Шундый да зур таш күтәргән!

Песи баласы үтә дә гайрәтле, батыр булган. Ләкин ул бәләкәй булган. Шуңа күрә басмадан ничек чабып чыгуын сизми дә калган.

Шул чабудан Аюны очратканчы туктамаган. Аюга тегенең галәмәт зур таш кизәнүе турында сөйләгән. Аю тагын бер киңәш биргән: «Син аңа озын таяк белән кизән. Таягыңнан куркыр да качар»,— дигән.

Песи баласы шулай иткән дә. Басмага озын таяк тотып кергән. Таягын күтәреп селтәнүе булган, теге тагын да озынрак һәм калынрак таягын шулай ук күтәреп селтәнгән. Куркуыннан Песи баласының таягы суга төшеп киткән. Ә үзе тиз генә борылган да, син күр дә мин күр, өйләренә кайтып җиткәнче чапкан.

Песи баласы әнисенә башыннан үткәннәрне сөйләп биргән.

— Минем төшке ашка күп балык тотып кайтасым килгән иде,— дип уфтанган.

— Теләгең булгач тотарсың да. Кайткан җиреңә кире кит. Ләкин тегеңә чыраеңны сытма. Кулыңа таш та, таяк та алма,— дигән әнисе.

— Нишлим соң? — дип сораган Песи баласы.

— Бар да аңа елмай.

— Шул җитәме? — дип сораган Песи баласы.

— Шул җитә,— дип җавап биргән әнисе.

Песи баласы үтә дә гайрәтле, батыр булган. Әнисе аның шундый булуына аз гына да шикләнмәгән.

Балыкчыбыз кабат буага киткән.

Барса, «ул» тагын суда басып тора икән.

Песи баласы басманың кыл уртасында туктаган. Әнисенең сүзләрен исенә төшергән. Үзен аска карарга һәм елмаерга мәҗбүр иткән.

Су төбендәге «ул» да аңа елмаеп җавап биргән.

Песи баласының шатлыгы эченә сыймаган. Шатлыгыннан кычкырып көлә башлаган. Аңа карап «ул» да көлгән. Шатланганда песиләр ничек көлсә, «ул» да шулай көлгән.

— Аның минем белән дуслашасы килә. Хәзер мин бер дә курыкмыйча ярның теге ягына чыга алам,— дигән үз-үзенә Песи баласы. Һәм агач өстеннән аръякка чапкан.

Бу юлы балыкчыбыз, аңа кул болгаган. Аны «ул» да кул болгап озатып калган.

Песи баласы аръякта бик күп балык тоткан. Балыкларын әнисенә алып кайткан.

— Минем моннан да тәмлерәк балыктан авыз иткәнем юк иде әле,— дигән әнисе.

— Моннан соң балыкка гел берүзем барачакмын. Мин хәзер буа төбендә утыручыдан бер дә

курыкмыйм. Бик ягымлы, әйбәт ул,— дигән Песи баласы.

— Беләм,— дигән әнисе.

Песи баласы әнисенә караган да:

— Әйт әле, буа төбендә утыручы кем ул? — дип сораган.

Әнисе көлеп җибәргән.

Аннары әйткән...

Лилиан Муур.

?! **1.** Әнисе баласына нәрсә дигән?

2. Әсәрнең төп герое — песи баласы. Вакыйгаларның бер өлеше аның батырлыгы, икенче өлеше куркаклыгы турында. Әсәр каршы якларга шулай бүленә. Песи баласы нигә батыр? Нигә куркак?

ОЗАК УЙЛАУЧЫ МАЛАЙ.

Юлдагы ташбаканы иң элек Лео күреп алды. Алар бөтен гаиләләре белән урманнан өйләренә кайтып баралар иде.

— Әти, туктат, ташбака! — дип кычкырды Лео.

Машина эченә керүгә, Ташбака кабырчыгыннан башын чыгарды. Шыксыз баш, озын тырнаклар күргәч, Леоның сеңелләре куркудан кычкырып җибәрделәр. Ә Лео аңа шунда ук гашыйк булды. Ташбакасына машинада ук исем бирде: «Син Чарли»,— диде.

Өйләрендәге эт Леоның әтисеннән башка берәүне дә санга сукмый. Ә песи үзенә үзе хуҗа булып яши. Шуңа күрә өйдә үз җәнлеге булуына Лео чиксез шат иде. Чарлины ул катыргы тартмага утыртты. Тартма почмагына редиска белән салат куйды. Ул бәхетле иде.

Лео кунагын уч төбендә генә йөртте. Кечкенә балаларны үпкән кебек, өзлексез үпте. Күкрәгенә куеп сөйде. Мәктәптән кайту белән, җилкәсенә куеп бүлмәдән бүлмәгә йөри торган булды. Ташбака борыны белән Леоның муенына төрткәләде. Алар икесе дә бәхетле иделәр.

Чарлины тапканда, Леога ун яшь иде. Озаграк уйлый торган малай булгангамы, дуслары күп түгел иде. Әтисе дә аны озак уйлыйсың дип шелтәләде. Дәрестә ул иң әкрен укый торган бала иде. Шуңа күрә аны башка бүлмәдәге салмаграк уйлаучылар янына чыгарып утырттылар. Лео бик кимсенде. Киләчәк тормышы аңа караңгы томан булып күренде.

Караңгы томанны Чарли гына таратты. Лео белгән ташбакаларның берсе дә Чарли кебек шәфкатьле түгел иде. Чарли башын яшермәде. Әле бер якка, әле икенче якка бора-бора, тирә-юньне күзәтте. Кулга алсаң, тирән диңгезне аркылы йөзеп чыга диярсең, аяклары белән тырыша-тырыша ишә башлый. Җиргә төшерсәң, бераз иснәнеп тора. Аннан соң, ашыкмыйча гына лап-лоп атлап, бүлмәләрне әйләнеп йөри.

Мәктәптән кайткан саен, Лео дустын урамга алып чыга. Урамда аңа мәктәптәге хәлләрне сөйли. Ташбакасына ничә яшь булгандыр. Ләкин күз төбендәге җыерчыкларына караганда, ул бик акыллы булып күренде. Шуңа күрә Лео аңа, көн дә серләрен сөйләп, күңелен бушатты.

Мәктәп урман янгынына каршы көрәш атналыгы үткәрде. Укучылар табигать турында фильмнар карадылар. Плакатлар язып элделәр... Лео укый торган сыйныф табигатьне саклау турында докладлар әзерләргә тиеш иде. Леога да доклад сөйләргә куштылар. Мәктәпкә ул, тартмасына салып, ташбакасын да алып барды.

Класска кергәч, тартманы тәрәзә төбендәге гөлләр арасына урнаштырды.

Балалар берәм-берәм сөйли башладылар. Берсе, янгында җәнлекләр янып үлә дип, бик күп җәнлекләр рәсемнәре күрсәтте. Алар бик кечкенә иделәр, шуңа күрә берәүгә дә күренмәделәр. Бер малай янган агач, сунарчылар турында нидер әйтте... Ниһаять, Леога да чират җитте.

Лео тартмасын алып укытучы өстәленә китереп куйды.

— Урманда янган шырпы ташлаучы кешедән дә юньсез кеше юк дөньяда,— дип башлады ул сүзен.— Андый кеше агачларны, кошларны һәм җәнлекләрне үтерә. Болан кебек тиз чабучы хайваннар, бәлки, чабып та котылырлар. Ләкин башкалары,— Лео тартмасыннан Чарлины чыгарып

күрсәтте,— менә мондый әкрен кыймылдый торганнары берничек тә котыла алмыйлар.

Лео нинди ташбакалар булуы, аларның бик матур һөнәрләре, ни яратулары турында бәйнә-бәйнә сөйләде. Чарлиның нинди гүзәл ташбака, чын дус булуын да әйтте. Аның сүзләре балаларга нык тәэсир итте. Алар ташбакаларны кызгандылар. Күңелләрендә урманны янгыннан саклау теләге артканнан-арта барды. Ихлас теләк иде ул. Ә укытучының күңеле тулып, күзләре яшьләнде.

Янгынга каршы көрәш атналыгының соңгы көне иде. Дәрестән соң мәктәп балалары спорт залында җыелдылар. Башта урманчы сүз алып сөйләде.

Аю һәм тиеннәр булып киенгән балалар биеделәр. Укучылар көлделәр, кул чаптылар. Лео башкаларга кушылып көләргәме, юкмы дип күңелсезләнеп утырды.

Иң соңыннан директор сөйләде. Ул сөйләгәндә Лео уе белән үзен өйләрендә итеп хис итте. Менә ул караватында ятып рәсем ясый. Ә Чарли идәндә әрле-бирле йөреп тора, имеш..

Аны уйларыннан күршедә утыручы укучылар бүлдерде.

— Әнә сине директор чакыра, тор,— диделәр.

— Кемне? Минеме? —дип сорады Лео, як-ягына карана-карана.

— Син беренче урынны алдың, бар! — дип кабатладылар укучылар.

Леоны, этеп-төртеп, алга таба җибәрделәр. Ул залның теге ягында директорның елмаюын күреп алды. Директор, аны үз янына чакырып, кулын селти иде.

Менә Лео алга үтте. Директорның кулын кысты. Тартмасын идәнгә куеп, Чарли белән бергәләп ясаган чыгышы өчен значок алды. Бу аның үз гомерендә беренче мәртәбә бүләк алуы иде. Директорга рәхмәт әйткәндә, Лео шатлыгыннан йөрәге ярылыр да сикереп чыгар дип курыкты.

Кичен ул, Чарлины җилкәсенә куеп, өйләрендә утырды. Беренче мәртәбә аңа җиңел иде. Алдагы тормышы турында уйлады. Анда томан юк иде.

Синтия Райлент.

?! **1.** Хикәяне өлешләргә бүлегез. Арадан иң әһәмиятле икесен аерып әйтегез.

2. Автор безгә, хәтта кимчелекләре булса да, һәр баланың үз матурлыгы бар. Шул матур сыйфатларны күрә генә белергә кирәк, ди. Авторның әнә шул киңәшен ачыклап сөйләгез.

Леоны да автор каршылыклы иткән. Аның кимчелеге бар. Ул әкрен уйлый. Аның бик матур сыйфаты бар: ул күпне белергә тырыша. Ул табигатьне ярата. Шундый ярата, хәтта үзе кебек әкрен кыймылдаучы ташбаканы да иң якын дусты иткән.

Каршылык алымы безне дә автор итә. Хәзер без әсәргә үзебездән әллә никадәр эчтәлек өсти алабыз. Мәсәлән, болай уйларга мөмкин.

Лео ни өчен мәктәптә табигатьне саклау турында сөйләп беренче урынны алды? Ул табигать турында да, үзенең яраткан ташбакасы турында да күп укыган. Дәрестә, ярышта сөйләр өчен түгел, үзе теләп укыган. Шуңа күрә ятлаганын кабатламыйча, һәр җөмләсен үз сүзләре белән, аңлаешлы итеп сөйләгән.

Бу хакта автор безгә берни дә әйтмәде. Без Лео күңелен үзебез күрдек. Аны шундый шәфкатьле булганы өчен яраттык. Хәтта ул яраткан ташбаканы да яратып өлгердек.

Хикәядә гүя без дә катнаштык. Үзебез дә сизмичә, тылсым дөньясында гиздек.

БЕР ТӘҢКӘ.

Бер карт өч улы белән яшәгән. Өлкән уллары эш яраткан. Ни эшләсәләр дә кулларыннан килгән. Төпчек улы кырга чыгарга ашкынып тормаган. Ялкаурак булган. Әтисе ни кушса да, берсен дә юньләп башкара алмаган. Көннәрнең берендә әтиләре улларына мондый киңәш биргән:

— Бу дөньядан китәр вакытым җитте. Сез, өлкән улларым, милекне урталай бүлеп алырсыз. Җирне дә шулай бүләрсез. Ә синең Петер хуҗалык эшенә кулың ятмый. Шуңа күрә бәхетеңне читтән табарсың. Үләр алдыннан әниең, сиңа бирергә дип, иске бер тәңкә калдырды. «Бу тәңкә кесәсендә чакта улым бернинди нужа күрмәс»,— диде. Тәңкәне өйдән читкә чыгып киткәндә бирергә кушты. Син аны әниең калдырган мирас итеп сакла. Әниең сине бик ярата иде,— дигән.

Әтиләрен җирләгәч, абыйлары Петерга бер атналык ризык биргәннәр.

— Бар, дөнья гиз. Бәхетеңне үзең эзләп тап,— дип, ерак юлга чыгарып җибәргәннәр.

Юлчыбыз кояш чыгышына карап киткән. Бара торгач, ашарына беткән. Арып, ачыгып басу уртасында ятып йоклаган.

Уянып китсә — янында ак сакаллы, бер күзле карт басып тора. Картның аяк очында өч кара эт ята.

— Эт сатам, алмассыңмы? — дип сораган карт.

— Ул этләргә ни ашатыйм, үзем дә ач утырам бит,— дигән Петер.

— Бу этләр үз тамакларын үзләре туйдыралар. Сине дә ач итмәсләр. Ышанмасаң карап тор.

Картның иң кечкенә этенә бармагын тидереп: «Ашарга китер»,— дияе булган, эт шунда ук күздән югалган. Ярты сәгать үткәнме-юкмы, кәрзин күтәреп әйләнеп тә кайткан. Ә кәрзин тулы кыздырылган тавык ите, балык, казылык... Егет туйганчы ашап, картка рәхмәт әйткән.

— Калган ризыгыңны этләргә бирерсең,— дип киңәш биргән аксакал.

— Бик алыр идем дә, бер генә тәңкә акчам бар шул,— дип уфтанган егет.

Аксакал шуңа да риза булган. Егетне:

— Этнең кечкенәсенә «ашарга китер», уртанчысына «ботарлап ташла», ә зурысына «тимер өз» дип эндәшерсең. Ярдәм кирәк чакта, үзеңә кирәк этне чакырырсың, теләгең шунда ук үтәлер,— дип кисәткән.

Бер күзле карт этләренә:

— Моннан соң хуҗагыз менә шушы булыр! — дип аңлаткан.

Этләр шунда ук Петер янына килеп, аның кулларын ялаганнар.

Китәр алдыннан, карт бармагы белән Петер җилкәсенә орынган. Егетнең бөтен тәне калтыранып куйган. Дөнья яктырып киткәндәй булган. Ул үзенең бик нык үзгәрүен сизгән.

Ә кич белән кесәсен капшаса, әлеге бер тәңкә үз урынында ята. Егет бу хәлгә хәйран калган. Аксакалга биреп җибәргән иде бит ул аны! Сынау өчен юлда очраган берәүдән, тәңкәсен биреп, иске киемен яңарагына алышкан. Ярты чакрым үткәндерме-юктырмы, тәңкә кабат кесәсенә әйләнеп кайткан.

Петер әнисе калдырган бер тәңкәнең тылсымлы булуын шунда гына белгән.

Ә беркөнне урман эченнән барганда, каршыларына дүрт ат җигелгән өсте ябык тарантас килеп туктаган. Эчтә елый-елый күзләре шешенеп беткән бер кыз утыра икән.

— Патша кызын аждаһага алып барам,— дигән кучер.

Кучер әйтүенә караганда, аждаһа аюга да, кошка да охшаган. Чаба да, оча да ала торган куркыныч нәрсә икән. Аңа ел саен уналты яшьлек кыз илтәләр. Илтмәсәң, тирә-юньдәге барлык хайваннарны, кешеләрне ашап бетерә икән. Быел җирәбә патша кызына төшкән.

Петер, этләрен ияртеп, кыз артыннан киткән. Тау сыртына җитүгә, югарыдан аждаһа төшеп килүе күренгән. Башында ике мөгез, тешләренең берсеберсе беләк буе булыр, тырнаклары озын, үткен... Менә ул патша кызы янына килеп җиткән. Кабып йотам дигәндә генә, Петер этенә: «Ботарлап ташла!» — дип боерган. Уртанчы эт шунда ук дошман өстенә ташланган.

Аждаһадан күпкә кечкенә булуына карамастан, эт аны күз ачып йомганчы ботарлап ташлаган.

Кыз, егеткә мең рәхмәтләр әйтеп, аны үзләренә кунакка чакырган. Әти сиңа кыйммәтле бүләк бирәчәк дип ышандырган. Ләкин юлчыбыз, патша янына барырга риза булмаган. Үз юлы белән киткән.

Кызны өйләренә алып кайтучы кучерның башына явыз уй килгән.

— Егеттән ярдәм сорап, сине мин коткардым бит. Шуңа күрә әтиеңә мине кучер коткарды дип әйтерсең. Югыйсә үтерәм,— дигән. Кыз курыккан. Ялганларга риза булган.

Кызының исән-сау әйләнеп кайтуын күргәч, патша бик шатланган. Аждаһаның җиңелүен ишеткән халык урамга бәйрәм итәргә чыккан. Ә кызын коткарган өчен, патша кучерга кыйммәтле бүләкләр биргән. Кызына өйләндерергә вәгъдә иткән. Ләкин бер ел көтик, кызым яшьрәк бит әле, дигән.

Кыз, әтисе сүзләрен ишеткәч, бик курыккан. Елаган да елаган. Антын бозмас өчен, дөреслекне берәүгә дә әйтә алмаган. Бер ел үткәч, әтисеннән туйны тагын бер елга кичектерүен үтенгән. Ә тагын бер ел үткәч, тагын бер ел сорап ялынган.

— Яхшылыкның кадерен белмисең. Үзеңне һәм бөтен патшалыкны үлемнән коткарган каһарманга кияүгә чыгарга теләмисең?!—дип ачуланган патша.

Кыз әтисенең алдына егылган.

— Ике ел элек аждаһа йоткан булса, бу хәсрәтләрне кичермәс идем! — дигән.

— Ярый, теләгеңне тагын бер генә елга үтим. Ләкин соңгы мәртәбә үтим,— дигән патша. Кыз этисенә рәхмәт әйткән. Ул әле һаман Петерның килүенә өмет иткән.

Тагын бер ел үткән. Халык туйга әзерләнгән. Шулвакыт шәһәргә, өч кара эт ияртеп, бер егет кергән.

Урамда бәйрәм итүче кешеләрдән егет: «Нигә болай шатланасыз?» — дип сораган.

— Бүген патша кызы үзен аждаһадан коткарган батырга кияүгә чыга,— дигәннәр.

Егет патша сараена килгән. Сакчылар кертмәгәч:

— Кызын ялганчы кешегә кияүгә бирә патша. Аждаһаны үтерүче кеше мин! — дигән. Ләкин аны, тиледер бу дип, төрмәгә япканнар.

Петер шунда гына ялгышын аңлаган. Нигә шулай сабырсызланып, артыгын сөйләп ташладым соң дип үкенгән. Кинәт тышта эт шыңшуын ишеткән. Аны этләре эзләп килгән икән. Егет этләренең иң зурысына:

— Тимер өз! — дип боерган. Эт тәрәзәнең тимер рәшәткәсен шунда ук челпәрәмә китереп өзгәләп ташлаган.

Котылганнан соң, егет кечкенә этенә ашарга китерергә кушкан. Ашамлык килгәч, кәрзин почмагына бәйләгән кулъяулыкны күреп алган. Кулъяулык эченнән алтын йөзек килеп чыккан. Җентекләбрәк карагач, аңа патша кызының исеме язылганын белгән.

Кәрзингә кульяулык болай бәйләнгән.

Кунаклар туй мәҗлесенә җыелу белән, бүлмәгә буш кәрзин капкан кара эт кергән дә патша кызы алдына килеп баскан. Эт кыз күзенә туп-туры карап, кулын ялаган. Кыз этне таныган. Егетнең шәһәргә кайтуын аңлап алган. Кәрзингә ашамлык салган арада, бер читенә, кульяулыкка төреп, йөзеген дә бәйләп өлгергән.

Эт шунда ук хуҗасы янына чапкан. Ә кыз әтисенә шыпырт кына нидер әйткән. Кызын патша күрше бүлмәгә алып чыккан. Бүлмәгә казыйны чакырткан.

— Үтерәм дип куркытып алынган антны бозарга ярыймы? — дип сораган патша казыйдан.

— Ярый,— дип җавап биргән казый.

Кыз әтисенә үзенең котылу вакыйгасын сөйләп биргән. Патша эт артыннан барып, егетне табып, сарайга алып килергә кушкан. Егет табылгач, патша кызы аны кочаклап алган:

— Бүген сез мине тагын бер аждаһадан коткардыгыз, рәхмәт сезгә,— дигән.

Патша, мәҗлес бүлмәсенә кереп, киявеннән:

— Башка берәү хезмәтен үзләштереп, ул аласы бүләкне алган кеше нинди җәза алырга тиеш? — дип сораган.

— Муенына таш бәйләп, упкынга ташларга кирәк андый кешене,— дип җавап биргән кучер.

— Бик әйбәт. Шулай булырга тиеш,— дигән патша һәм залга Петерны чакырткан. Өч эт ияртеп

кергән егетне күргәч, кучер, шәфкатьлелек сорап, патша алдына тезләнгән.

— Кабахәт! Җәзаны син үзең әйттең,— дигән аңа патша һәм кучерны, богаулап, залдан алып чыкканнар.

Петер капчыгыннан аждаһаның мөгезләрен һәм тешләрен чыгарып күрсәткәч, кунаклар шаугөр килеп кул чапканнар. Патша егетне үз янына утырткан. Туй мәҗлесен дәвам итәргә боерган. Кызын Петерга биргән.

Беркадәр вакыт үткәч, яшьләр егетнең туган авылына кайтканнар. Петер туганнарына кыйммәтле бүләкләр биргән. Моннан соң да хуҗалыкларын алып бару өчен ярдәм итеп торган. Ә әнисе калдырган бер тәңкәлек мирасны өлкән абыйсына тоттырган.

— Төпчек улың бәхет эзләп читкә киткәндә бирерсең. Әни тәңкәсе ул. Кыен чакта ярдәм итәр,— дигән.

?! **1.** Әкиятне өлешләргә бүлеп, исемнәр бирик:

1) мал бүлешү;
2) ярдәм итүче этләр хуҗасы;
3) ялган;
4) ялганның фаш ителүе;
5) ана мәхәббәте.

Шул өлешләрне исегезгә төшереп сөйләгез.

2. Өлешләрдәге вакыйгаларны исегезгә төшерегез.

Әкият авторлары безне бөтенләй башка бик гүзәл тылсымлы дөньяга алып керә. Анда күз күрмәгән, колак ишетмәгән вакыйгалар, гаҗәеп катнашучылар белән очрашабыз. Без юлаучы картның тылсымлы этләрен бер тәңкәгә сатуына да, андый тылсымлы этләрнең булуына да, аждаһага да ышанмыйбыз, әлбәттә. Ләкин без әкият дөньясында йөрибез бит. Ә әкият дөньясында теләсә ни булырга мөмкин. Шуңа күрә сукыр картка да, тылсымлы этләр, аждаһалар яшәвенә дә ышанасыбыз килә.

?! Әкияттәге могҗиза дөньясында гына була торган нәрсәләрне табыгыз.

Әкияттәге төп каршылык мондый: әкият башында егет ялкау. Шуның өчен әтисе аны, нибары бер тәңкә тоттырып, өеннән чыгарып җибәрә. Ләкин ахырдан егет мактанырлык эшләр башкара, башкаларны бәхетле итә. Үзе дә бәхетле була. Кыскартып әйтсәк, булдыксыз егет булдыклыга әйләнде. Менә шундый каршылык.

Әсәргә без ничек катнашабыз?

Без әсәрдәге шул каршылыкның сәбәбен эзләп табабыз. Ә аны табу бер дә читен түгел. Әйдәгез, бергәләп уйлыйк.

Әкият авторлары башкалар рәнҗеткән геройларын һәрвакыт яклыйлар. Аңа төрлечә ярдәм күрсәтәләр. Бу әкияттә, мәсәлән, кыерсытылган

малай кесәсенә тылсымлы тәңкә салалар, барыр юлына тылсымлы этләр бүләк итүче картны китереп бастыралар. Егетне бәхетле иткән бүләкләр арасында бер тәңкә акча аеруча кызыклы. Ул тәңкә егетне күп бәлаләрдән коткара. Нибары бер генә тәңкә, ә үзе әнә нинди могҗизага ия дип сокланабыз. Тәңкә аны киендерә, тамагын туйдыра, патша кияве итә. Нибары иске бер генә тәңкә әнә ничек ярдәм итә?

Тагын уйны эшкә җигәбез. Тәңкәнең сыйфатларын искә төшерәбез.

— Ә-ә-ә! Улына әнисе мирас итеп калдырган тәңкә бит. Иң кыен чакта ярдәмгә килергә тиешле бүләк! Әнисе калдырган ярдәм. Менә ничек! Ул тәңкә — тәңкә генә түгел, ананың улына чиксез мәхәббәте дә бит! Егеткә иң кыен чакта күптән дөньядан киткән әнисенең мәхәббәте ярдәмгә килә! Без шул могҗизага ышанабызмы? Нигә ышанмаска? Әни мәхәббәте бит ул! Әни мәхәббәте барыбызның да күңел түрендә утыра. Ул һәрчак безнең белән.

ЙОЛДЫЗ УЛЫ.

Урман кисүче ике кеше эштән кайта. Икесе дә алама киемнән, ә көн бик салкын. Дуслар тормыш авырлыгыннан зарлана-зарлана кайталар.Тирән кар ерып бара торгач, көтмәгәндә адәм ышанмаслык вакыйгага тап булалар.

Баш очларындагы бер йолдыз атылып җиргә төшә. Күз нурларын алырлык якты, гүзәл йолдыз була ул.

— Карале, безнең бәхеткә күктән алтын төште бит! — дип кычкырып җибәрәләр урманчылар. Шулай кычкыра-кычкыра, йолдыз төшкән урынга чабалар.

Барып җитсәләр, кар өстендә алтын тукымадан тегелгән бишмәт күрәләр. Аңа затлы җепләрдән йолдызлар чигелгән. Ә бишмәт эчендә бала йоклап ята.

— Без икебез дә ярлы кешеләр бит. Үз балаларыбызны ашатырга да икмәк юк. Калсын шунда,— ди урманчыларның берсе.

— Юк, мин андый яманлык эшли алмыйм. Өйгә алып кайтам. Ул да — җан иясе бит. Башка балалар арасында ничек тә үсәр әле,— ди икенчесе.

Урманчылар бераздан үз авылларына кайтып китәләр.

Бала күтәргән урманчы, өйләренә кайтып җитеп, ишекләрен шакый. Хатыны аны шатланып каршы ала. Шушы салкында ерак юлдан исән-имин кайткач, ничек шатланмасын, ди.

Ләкин урманчы ишек тупсасын атлап керер алдыннан.

— Урманда табышлы булдым. Син карап үстерер дип бала алып кайттым,— ди. Бишмәтне ачып җибәрә дә хатынына баланы күрсәтә.

— Безгә шул гына җитмәгән иде. Үз балаларыбызның тамагын ничек туйдырырга белмибез, мә сиңа — тагын бала,— дип ачулана хатыны.

— Кеше баласы түгел ул. Йолдыз баласы,— ди ире һәм күктән йолдыз атылуы турында сөйләп бирә.

Шактый вакыт узгач, хатыны, елый-елый, ирен мич каршына чакыра. Ире баланы хатынының итәгенә яткыра. Хатыны баланы үбә дә, кече улы янына бишеккә сала.

Күктән төшкән алтын бишмәтне һәм бала муенындагы гәрәбә муенсаны сандыкка яшереп куялар.

Йолдыз улы урманчының башка балалары белән үсә. Алар белән бергә утырып ашый, бергә уйный. Үскән саен матурая бара. Авыл халкы аның матурлыгына сокланып туя алмый. Йолдыз улының йөзе ап-ак, чәч бөдрәләре алтын төстә, иреннәре ал гөлчәчәккә охшаган. Күзләре — әйтерсең лә миләүшә чәчәгенең суга төшкән шәүләсе!

Ләкин матурлыгы аңа бәла генә китерә. Чөнки ул үзен генә яратучы, рәхимсез, тәкәббер булып үсә. «Мин йолдыздан туган, ә сез ярлылар. Шуңа күрә сез минем коллар»,— дип, башка балаларны кимсетә. Хәерчеләрне һәм имгәнгән, ярдәмгә мохтаҗ кешеләрне кызганмый. Аларга таш атып кала. Алай да балалар аның сүзенә каршы килмиләр, чөнки Йолдыз улы башкалардан тизрәк

йөгерә, алардан остарак бии, җырлый, кубызда уйный.

Көннәрнең берендә авылдан бер бәхетсез хәерче хатын үтә. Мескеннең өс киеме тетелеп беткән. Аяклары яргаланып, канга буялган. Тәмам арып-талып, ял итәргә дип, карчык агач төбенә утырган.

— Пычрак, ямьсез хәерче нинди матур яшел агач төбендә утыра. Әйдәгез, куып җибәрик моннан! — дип кычкыра Йолдыз улы иптәшләренә. Ә үзе аңа, яман сүзләр әйтә-әйтә, таш ата. Хәерче хатын кинәт сискәнеп китә. Малай йөзенә текәлә дә, күзен алмыйча, туп-туры карап тора. Урман кисүче койма буенда балтасы белән киртәләр юна икән. Бу хәлне күреп, малайны ачулана башлый:

— Йөрәгең таш икән. Кызганучның ни икәнлеген дә белмисең. Бу хатынның сиңа ни зыяны тиде? Нигә куасың аны? — ди.

— Нигә миңа акыл өйрәтәсең! Мин синең улың түгел. Шуңа күрә мине өйрәтергә хакың юк! — дип кычкыра Йолдыз улы.

— Дөрес. Улым түгел. Мин сине урманнан табып өйгә алып кайтуыма үкенеп туя алмыйм,— ди урманчы.

Бу сүзләрне ишеткәч, хәерче хатын һушыннан яза. Карт аны өйләренә күтәреп кертә. Хатын һушына килгәч:

— Син ул малайны, чыннан да, урманнан таптыңмы? Аның янында тагынниләр бар иде?

Муенында гәрәбә муенсасы юк идеме? Алтын бишмәткә төрелмәгән идеме? — дип сорый.

Урманчы сандыгыннан бишмәт белән муенса алып бирә.

Хатын аларны кулына алгач елый-елый да:

— Ул малай минем кече улым. Мин аны урманда югалттым. Зинһар, чакырып кертә күр,— дип ялвара.

Малай, әни белән очрашам дип, шатланып керә. Ләкин каршында агач төбендәге елап утыручы хәерче карчыкны күргәч, кинәт йөзе үзгәрә:

— Минем әни шушы хәерчеме?

— Синең әниең мин.

— Әллә акылдан шаштыңмы, хәерче! — дип кычкыра Йолдыз улы.— Мин ничек синең улың булыйм? Син бит иске-моcкы бөркәнгән гарип хәерче. Тай моннан. Синең хәшәрәт битеңне күрәсем дә килми!

Хатын улы алдына тезләнә дә, ике кулын сузып, елый-елый:

— Мин сине, улым, урманда таптым. Сине юлбасарлар урлады да, шушында үлсен дип, ташлап киттеләр. Мин бит сине бер күрү белән таныдым. Әйберләреңне дә таныдым. Алтын киемгә сине мин төрдем, муеныңа менә бу гәрәбә муенсаны мин астым. Ялварып сорыйм, әйдә, бергә китик. Сине эзли-эзли мин бөтен дөньяны әйләнеп чыктым бит,— ди.

— Чыннан да минем әни булсаң, монда килмәвең хәерлерәк булыр иде. Мин моңа кадәр әнием

«йолдыз» дип горурланып йөрдем. Ә син хәерче икәнсең. Хәзер үк кит моннан. Күземә күренмә! — ди улы.

— Бер генә тапкыр да үпмисеңме мине, улым?

— Сине үпкәнче мин еланны үбәр идем,— дип җавап бирә улы.

Хатын, елый-елый, урманга кереп китә. Улы малайлар янына уйнарга чаба.

Ләкин малайлар аның белән уйнаудан баш тарталар. Син бака кебек хәшәрәт, агулы елан кебек юньсез! — дип, яннарыннан куалар.

Йолдыз улы: «Нигә миңа хәшәрәт, диләр. Су буена барып карыйм әле үземне»,— дип, күл буена китә. Судан үзен күргәч егыла яза: йөзе гөберле бакага охшаган, тәне елан кабыгы диярсең, кабырчыклар белән капланган.

Малай, үләнгә ятып, үкси-үкси елый.

— Әнидән баш тарткан өчен, миңа Алла биргән җәза бу. Бөтен дөньяны әйләнсәм әйләнермен, ләкин әнине эзләп табармын. Гафу үтенермен. Зинһар, әнием, мине кичерә күр, югыйсә бу дөньяда яши алмаячакмын диярмен,— ди.

Менә ул әнисен эзләп урманга чаба. Урман эчендә йөри-йөри: «Әни! Син кайда? Кайт, әни, кайт, мин монда!» — дип кычкырып әнисен эзли. Ләкин җавап ала алмый. Кояш баегач, үлән арасына кереп йоклый. Аны күреп бөтен кош-корт, җанвар бу тирәдән кача. Алар әнисен рәнҗеткән малайның янәшәсендә дә торырга теләмиләр.

Малай, таң атуга ниндидер әче җимеш табып ашый да, урманның иң куе урынына кереп китә.

Сукыр тычканны очрата.

— Минем әнине күрмәдеңме? — дип сорый.

— Син бит минем күземә таш белән бәрдең. Мин ничек күрим? — дип җавап бирә Сукыр тычкан.

Чыпчыктан: .

— Син агачлардан да биегрәк очасың. Минем әнине күрмәдеңме? — дип сорый.

— Кызык ясап, син бит минем канатымны кистең. Ничек очыйм,— дип җавап бирә.

Тиеннән сорый. Тиен аңа:

— Син минем әнине бәреп үтердең. Бәлки, үз әниеңә дә бер-бер зыян ясар өчен эзлисеңдер! — дип җавап бирә.

Өч ел буе дөнья гизеп әнисен эзли малай. Аңа берәү дә ярдәм кулы сузмый. Берәү дә кадер-хөрмәт күрсәтми.

Көннәрнең берендә ул бер шәһәр капкасы каршына барып җитә. Сакчыларга әнисен эзләвен әйтә. Мин дә әни кебек хәер сорашып яшим, ди. Сакчылар башлыгы көлеп җибәрә.

— Бик әйбәт, без бу хәерчене кол итеп сатып җибәрик, — диләр.

Малайны тотып, кулларын бәйләргә җыенганда, каяндыр усал чырайлы бер карт килеп чыга. Карт Йолдыз улын сакчылардан сатып ала. Җитәкләп шәһәр урамнарыннан китә. Күзен ефәк шарф белән бәйләп, ниндидер бинага алып керә. Ефәк яулыкны

күзеннән алгач, малай үзенең караңгы базда булуын белә. Карт малай алдына каткан ипи белән су кертеп куя да ишекне тыштан бикләп чыгып китә.

* * *

Карт явыз сихерче икән. Икенче көнне иртүк малай янына кереп:

— Шәһәр капкасы каршында кяферләр урманы бар. Анда өч алтын тәңкә күмелгән. Берсе ак, берсе сары, берсе кызыл алтыннан булыр. Бүген син миңа ак алтынлысын табып китер. Китермәсәң, йөз камчы алырсың,— ди һәм урман эченә озатып куя.

Урманның эче тулы чәнечкеле чытырман икән. Йолдыз улы, аяк-кулларын сыдырта-сыдырта кичкә хәтле эзләсә дә, тәңкәне таба алмый. Елый-елый урманнан чыкканда, ялварган тавыш ишетә. Бер Куян баласы аучы капкынына эләккән, икән. Малай Куян баласын коткара :

— Мин, үзем кол булсам да, сиңа ирек бирәм,— ди.

— Миңа ирек бүләк иткән өчен, сиңа нинди яхшылык эшли алам? — дип сорый Куян баласы.

— Мин ак алтын тәңкә эзлим, тапмасам, хуҗам камчы белән кыйнаячак,— ди малай.

Куян аны иске имән куышына алып килә. Тәңкә шул куыш төбендә ята икән. Малай куян баласына мең рәхмәтләр әйтә. Тәңкәне алып кайтырга чыга.

Юлда чире йөзенә чыккан теләнче очрый. Теләнче кыңгыравын шалтырата да:

— Хәер бирмәсәң, шушында егылып ачтан үләчәкмен. Мине бу шәһәрдә кызганучы кеше юк, коткара күр, — дип ялына.

— Бердәнбер тәңкәм бар. Әгәр аны алып кайтмасам, хуҗам мине кыйнаячак. Мин аның колы,— ди малай. Ләкин, хәерче бик ялварып сорагач, алтын тәңкәсен аңа биреп калдыра.

Тәңкәсез кайткан малайны сихерче арганчы кыйный. Алдына буш савыт куя да: «Мә, аша»,— ди.

Икенче көнне иртүк малайны сары алтын эзләргә җибәрә. Бу юлы да Йолдыз улына Куян баласы ярдәм итә. Малай эзләгән тәңкәне ул табыша.

Кайтышлый әлеге ямьсез чырайлы кеше тагын очрый. Ачтан үтерә күрмә, дип ялвара. Малай бу юлы да сары төстәге алтын тәңкәсен биреп калдыра.

— Сары алтын тәңкәне алып кайттыңмы? — дип сорый капка янында көтеп торган сихерче.

— Юк,— дип җавап бирә малай.

Сихерче малайны бик каты кыйный. Кулларына богау сала һәм караңгы бүлмәгә ябып куя.

Икенче көнне кереп:

— Бу юлы кызыл алтын тәңкәне алып кайтсаң — азат итәм, алып кайтмасаң — үтерәм,— ди.

Урманны аркылыга-буйга йөреп көне буе эзләсә дә, малай эзләгәнен таба алмый. Кояш баеп

караңгы төшкәч, агач төбенә утыра да үкси-үкси елый. Шулай елап утырганда, Куян баласы чабып килә дә:

— Син эзли торган алтын тәңкәнең кызылы артындагы тау куышында,— ди.

— Мине өч тапкыр бәладән коткардың инде. Сиңа нинди рәхмәтләр әйтергә дә белмим,— ди малай.

— Мин бәладә чакта иң элек син кызгандың,— дип җавап бирә Куян баласы һәм куак эченә кереп югала.

Йолдыз улы, кызыл алтыннан ясалган тәңкәне табып, кайтыр юлга чыга. Юлда аңа тагын ямьсез чырайлы теләнче очрый. Бу юлы да ул:

— Кызыл алтыннан эшләнгән тәңкәңне бирмәсәң, мин үләм,— дип ялвара.

Йолдыз улы аны кызгана. Кызыл алтын тәңкәсен биреп калдыра.

— Синең язмышың минекеннән дә яманрак,— ди. Ләкин кайткач үзен ни көтәсен исенә төшереп калтыранып куя.

* * *

Дөньяда могҗиза юк, диләр. Бар икән. Шәһәр капкасы ачылгач, сакчылар аны баш иеп:

— Безнең хуҗабыз нинди чибәр! — дип, мактый-мактый каршы алалар.

Ә шәһәр урамыннан үткәндә, халык:

— Мондый чибәр малай дөньяда юктыр,— дип соклана.

— Миннән көләләр,— дип уйлый Йолдыз улы һәм хурланып елый.

Озатып килүче кешеләрне ера-ера бара торгач, малай юлын адаша. Ялгыш патша сарае янына килеп чыга.

Ул арада сарай капкасы ачыла. Аннан патшаның иң абруйлы түрәләре чыга. Алар, малай алдында башларын түбән иеп:

— Син безнең хуҗабыз. Патшабызның улы. Без синең кайтканны күптән көтәбез,— диләр.

— Мин патша улы түгел. Хәерче хатын улы. Минем кыяфәтем дә адәм карарлык түгел,— ди малай.

Шуннан соң сакчыларның берсе калканын күтәрә дә:

— Менә моңа кара да үзеңне күр. Нигә безгә ышанмыйсың? — ди.

Йолдыз улы калканга карый һәм шакката: калкан-көзгедән аңа элеккечә чибәр малай карап тора. Шул ук малай, тик күзләрендә генә ниндидер башка нур бар.

Патша түрәләре малай алдында тезләнәләр.

— Пәйгамбәр безгә шушы көнне ил белән идарә итүче килер, дигән иде. Менә син килдең безнең патшабыз бул,— дип ялыналар.

— Мин патша булырга лаек түгел. Мин үз әниемнән баш тарткан малай. Аны табып гафу

үтенергә тиеш. Алдына тезләнеп, елый-елый тәүбә итәргә тиеш. Мин әнине эзләргә китәм,— дип җавап бирә Йолдыз улы.

Китәргә дип борылуы була, хәерче киемендәге әнисен күреп ала. Әнисе янында усал чырайлы теләнче карт та басып тора. Йолдыз улы шатлыгыннан кычкырып җибәрүен үзе дә сизми кала. Менә ул әнисе янына ташлана. Аны бертуктаусыз үбәргә тотына. Аякларындагы яраларын күз яшьләре белән юа. Үкси-үкси елап әнисенә:

— Әнием, бәгърем! Мин тәкәбберлегем белән сине янымнан куып җибәрдем. Хәзер акылга утыргач, елый-елый сорыйм, зинһар, мине элеккечә ярат, яныңнан кума. Улың итеп кабул ит! — ди.

Ләкин хәерче хатын җавап бирми.

Малай усал чырайлы теләнчегә таба кулын суза.

— Әнине бер генә сүз белән булса да җавап бирергә күндерә күр,— ди.

Ләкин теләнче дә җавап бирми.

Йолдыз улы үкси-үкси елый:

— Әнием, бәгърем, мин бу хәсрәтемне күтәрә алмыйм. Мине гафу итә күр. Үзебезнең урманга кайтырга рөхсәт ит,— ди.

Хәерче хатын белән теләнче кулларын малай башына куялар.

— Тор,— диләр.

Малай аягына баса һәм ни күзе белән күрсен — аның каршында патша белән патша хатыны басып тора.

Патша хатыны улына:

— Син ач үлемнән өч тапкыр коткарган теләнче каршыңда басып тора. Ул синең әтиең,— ди.

— Күз яшең белән аягындагы яраларын юган әниең каршыңда басып тора, — ди әтисе.

Ата белән ана улларын, үбә-үбә, сарайга алып керәләр. Аңа затлы киемнәр киендерәләр. Башына таҗ куялар — патша итәләр. Йолдыз улы бик игелекле патша була. Халыкка күп ярдәм итә. Кешеләрне шәфкатьле, мәрхәмәтле, гадел булырга өйрәтә. Кош-кортны, хайван-җәнлекләрне рәнҗетмәскә боера. Хәерчеләрнең тамагын туйдыра, ялангачларга кием бирә. Явыз сихерчене илдән куа. Ә урман кисүчегә һәм аның хатынына кыйммәтле бүләкләр җибәрә.

Ләкин Йолдыз улы патша булып озак идарә итә алмый. Башыннан үткән интегүләре, хәсрәтләре аны өч ел үтүгә бу дөньядан алып китәләр.

Оскар Уайльд

?! **1.** Безнең төп герой — Йолдыз улы. Ул катнашкан вакыйгалар мондый:

1) Йолдыз улының яман эшләре; 2) җәза алуы; 3) үкенүе; 4) гафу үтенүе; 5) гафу ителүе.

Биш өлешне, ике генә өлешкә калдырып, тагын бер тапкыр кыскартыгыз. Йолдыз улына бәя бирегез. Башта сез аның кылануын күреп нәфрәтләнәсез. Аннары нишлисез?

2. Әсәрдәге ана мәхәббәте турында сөйләгез.

ӘТИНЕҢ ТУТЫЙ КОШЫ.

Гарриның әтисе татлы ашамлыклар кибетендә сатучы булып эшли. Гарри әтисе белән горурлана. Гаррига җиде яшь тулганда, алар дуслар иде. Унике тулгач та дус булып калдылар.

Гарри мәктәптән соң әтисе эшли торган кибеткә керергә гадәтләнә. Ул әтисенең ничек эшләвен күзәтеп торырга ярата. Кибеткә дусларын ияртеп кергән чаклары да була. Алар төрле-төрле тартмалардан берничә сумлык кына конфет сайлап алалар, кыздырылган чикләвек ашап карыйлар. Тиллиан агай улының дуслары белән керүен көтеп ала. Аларны тәм-том белән сыйлый.

Ләкин башлангыч мәктәпне тәмамлаганнан соң, Гарри кибеткә сирәк керә торган булды. Дуслары да бик сирәк күренде. Хәзер алар буфетларга кереп ашадылар, компьютерда уйнадылар, пластинкалар җыйдылар. Андый чакта конфет белән чикләвек онытыла икән ул.

Гаррига унике яшь тулгач, әтисе соңгы акчасына тутый кош сатып алды. Читлеген кибетенә элеп куйды һәм кошка «Рокки» дип исем кушты. Әтисенә Гарри: «Сиңа тутый кош нигә кирәк?» — дип әйтеп карады. Ләкин әтисе җавап бирмәде.

Тиллиан агай Рокки белән тату яшәде. Алар бергәләп телевизор карадылар. Фильм караганда җыр ишетсә, Рокки көйгә кычкырып кушылырга яратты. Аларга шулай яшәү күңелле иде.

Көннәр үткән саен, Тиллиан агай тутый кошын ныграк яратты. Хәзер ул аның белән көннәр буе сөйләшеп йөрде. Кибет яныннан үткәндә, Гарри тәрәзәгә күз ташлый. Ничә карамасын, әтисенең тутый кошына нидер әйтеп торуын күреп гаҗәпләнә. «Кош белән ни турында сөйләшергә мөмкин»,— дип, бераз басып тора да китеп бара.

Өйдә аш алдында әтисе белән улы юри бер-берсен үртәшеп утыралар. Носкиың юмаган, ди әтисе. Гарри әтисенең зур корсагыннан көлә. Өйдә бар да тәртиптә кебек.

Ә беркөнне Тиллиан агай эш урынында егылды. Конфет тартмаларын ачканда, күкрәген тотты да ауды. Аны «ашыгыч ярдәм» машинасы алып китте.

Хастаханәдә ул озак ятты. Хәле начар булса да, кибетен кайгыртты, конфет, чикләвек китерергә тиешләр иде, китерделәр микән, Рокки ач утыра торгандыр дип, үз-үзенә сөйләнде.

Гарри әтисен юатырга тырышты. Дәресләр тәмамлангач, көн дә кибеткә кереп чыгарга, килгән тартмаларын ачып, конфет, чикләвекләрне үз урыннарына куярга, Роккины туйдырырга сүз бирде.

Дәрестән соң Гарри бу юлы дусларына ияреп китмәде. Кибеткә килде. Аның бервакытта да кибетне ябык килеш күргәне юк иде. Ачып керде. Ут яндырды. Әтисен алып киткәннән бирле монда аяк басучы кеше булмаган. Конфетлар, чикләвекләр чәчелеп ята. Гарри аларны җыештырып

тартмаларына тутырганда, тутый кош дәшми генә карап торды.

Егет, ачылмаган тартмаларны ачып, андагы конфет, чикләвекләрне дә үз урыннарына урнаштырды.

— Сәлам! — диде кемдер.

Гарри урыныннан сикереп торды. Хәтта бер тартмасын кулыннан төшереп үк җибәрде.

— Сәлам, Рокки!

Гарриның күзләре тутый кошка текәлде. Ул аның барлыгын да оныткан иде.

— Сәлам, Рокки,— дип җавап бирде тутый кош. Гарри читлек янына килде. Кошның ашарына беткән, суы пычранган иде.

Гарри читлекне бүлмәгә кертте.

— Бүтән сүз белмисеңме әллә син, ахмак кош? — дип сорады. Кош җавап бирмәде. Гарри читлекне тазартып, эченә азык, су салды һәм үз урынына элде. Конфетларны урнаштыру эшенә тотынам гына дигәндә, тутый кош:

— Гарри кайда? — дип кычкырды.

Гарри, аптырап, кошка карады.

— Гарри кайда? — дип кабатлады кош.

Гарри калтыранып китте: «Нигә минем исемне әйтә ул? Ни өчен?»

— Гарри кайда?

— Монда мин, ахмак кош, монда! — дип кычкырды Гарри.

— Ахмак кош! — диде тутый кош.

— Ниһаять, дөресен әйттең,— диде Гарри.

— Гарри кайда? Ансыз күңелсез. Ансыз күңелсез. Ахмак кош!

Гарри, бер уч конфет алып, читлек янына килде.

— Мин монда, дидем бит. Ишетәсеңме, ахмак кош! Мин монда,— диде Гарри һәм читлек эченә конфет ташлады.

Тутый кош, кычкыра-кычкыра, тырнаклары белән читлектәге таякка ябышты.

— Мин монда,— диде Гарри, бу юлы ишетелер-ишетелмәс кенә итеп. Башын иде дә елап җибәрде.

— Әти! — Гарри куллары белән йөзен каплады.

— Гарри кайда?

Гарри, авыр сулап, җиңе белән күз яшьләрен сөртте. Тутый кошка карады да кинәт аңлады: димәк, аңа әтисе күп тапкыр «Гарри кайда соң? Ансыз күңелсез бит» дип кабатлаган.

Гарри конфетларны урнаштырып бетерде. Тутый кошка салкын булмасмы дип, җылыткыч батареяларны тотып карады һәм хастаханәгә әтисе янына китте.

Синтия Райлент

?! **1.** Хикәяне кыскартып сөйләгез.

2. Гарри әсәр башында да әтисен ярата. Әсәр соңында да ярата. Аермасын әйтегез.

ИШЕГАЛДЫНДА.

Ишегалды булса да тар,
Һәркемнең үз шөгыле бар.

Бакча ягын күзли сарык:
Ул сыярдай юкмы ярык?
Печәнлектә мәче поскан,
Тын да алмый саклый тычкан.
Үзалдына нидер җырлап,
Әтәч йөри нидер тырмап.
Кабарынып, ата күркә
Басып тора шундый текә.
Кәҗә генә көяләнгән —
Сакалы шул чияләнгән.

Көяләнми — эше харап,
Әллә кая киткән тарак.
Шуклыклары күп тәкәнең:
Сөзеп екккан су тәпәнен.

Иркәләнеп казлар ята,
Ә үрдәкләр акыл сата.
Әле монда, әле анда
Чабып йөри Хәсәнҗан да.
Чапмас иде, тик торалмый,
Торыр иде — булдыралмый.
Сүз итмичә калмый сүзен,
Котыртучы да юк үзен!
Әле тәкәгә атлана,
Тәкә ыргый — ул каплана.
Егылса да еламый ул.
Күркәгә дә тиеп китә,
Кәҗәгә гел тибеп китә.
Куркып бар да кача аннан —
Орчык кадәр Хәсәнҗаннан.
Сүз әйтүче, тыючы юк.
Аңа каршы чыгучы юк.

Инде эшләр моңа киткәч,
Ачуыннан кызып киткәч,
Тавыкларга тигән өчен,
Алды әтәч аннан үчен:
Каршысына килеп чыкты,
Хәсәнҗанны тибеп екты.

Хәзер инде бар да батыр.
Күркә кәлә: «Колтыр-колтыр!»
Тарак эзләвен дә онтып,
Кәҗә кәлә эчен тотып.
Барча үрдәк: «Бак-бак!» килә,
Ауный-ауный казлар кәлә.
«Бә-ә, бә-ә!» — дип кәлә сарык,
Кәлә-кәлә, печәнлектән
Кара мәче төште барып,
Тавык кәлә: «Кырра-кырра!» —
Ә Хәсәнҗан елап тора.

Нур Әхмәдиев.

?! **1.** Шигырьдәге беренче каршылык: Хәсәнҗан башта батыр. Соңыннан куркак. Ул ни өчен батыр? Ни өчен куркак?

2. Тагын бер каршылык табыгыз.

КОМЛЫ КОМСЫЗ.

Кадыйрларның комы бик күп —
Капка төбе тау кебек.
Килде күрше малайлары,
Көтү төсле шау килеп.
— Комы да комы,— диләр,—
Кем өйде моны? — диләр.
Зур өемгә ятып Кадыйр
Ауный, уйный, таптана,
— Әтием тагын бер машина
Кайтара! — дип мактана.
Шатланышалар малайлар:
— Йомшак икән, кайнар да,
Рәхәтләнеп кызынырбыз,
Кызык булыр уйнарга!

Кадыйр аларга ни әйтә?
Ул аларга шуны әйтә:
— Уйнамый торыгыз,— ди,—
Бу безнең комыбыз! — ди.
Шулай ди дә уйный бирә,
Берүзе тавыш-тынсыз.
Малайлар китә борылып:
— Берүзең уйна, комсыз!
Ком тавында уйный Кадыйр,
Ясый ул әллә ниләр.
«Комым күп бит, нигә миңа
Малайлар «комсыз!» диләр?!»

Шәүкәт Галиев.

?! **1.** Катнашучылар турында сөйләгез. Алар сезгә ошыймы, ошамыймы? Ни өчен ошый? Ни өчен ошамый?

2. Кадыйр нәрсәне аңламый?

3. Шигырьдә иң әһәмиятле сүзне табыгыз.

4. Кадыйр турында язып, автор безгә нәрсә әйтергә тели?

5. Авторга бу шигырьне иҗат итәргә ярдәм иткән каршылыкны табыгыз.

Каршылык катнашкан берничә әсәр белән таныштык. Ул әсәрләрдә каршылык ни эшләде? Берәм-берәм искә төшерик. Бәйләнешнең якын туганы — каршылык катнашучыларны татулаштырды, хаталарын танырга мәҗбүр итте. Яман эшләүчеләрне төзәтте.

Ятлау өчен.

ТУГАН АВЫЛ.

(Өзек.)

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.

Габдулла Тукай.

БӘБКӘЛӘР.

Әйләнә-тирәләрдә,
Ямь-яшел чирәмнәрдә,
Япь-яшь бәбкәләр йөри,
Чирәм тартып өзгәндә,
Койрыгын җиргә тери.
Йоннары йоп-йомшак,
Тәпиләре гәрәбә,
Кызыгам бер сөяргә!
Алар бик сөйкемлеләр,
Уенчык шикеллеләр.

Шәйхи Маннур.

ЧЫК БӨРТЕГЕ.

(Өзек.)

Яшь үләнгә
Кунды иртән
Чык бөртеге,
Һәрнәрсәне
Үзенә тарта —
Ул бик тере.

Шул чагында
Тау артыннан
Кояш чыкты,
Күреп алды
Үләндәге
Матур чыкны.

Чык үзе дә
Күрү белән
Гашыйк булды,
Бит уртасы,
Чокырланып,
Нурга тулды...

Сибгат Хәким.

ҮЗЕ ЗӘҢГӘР КҮЗЛЕ.

Карлар китмәс димә,
Язлар җитмәс димә.
Арыш кырларыннан
Арып, апрель килә.
Үзе зәңгәр күзле,
Үзе җитен чәчле.
Хәтфә болыннарга
Гөл-чәчәкләр чәчте.

Гамил Афзал.

БЕЗ — КОЯШ БАЛАЛАРЫ.

Туган якта куәт җыйгач
Китәрбез әле ары.
Күзләр күктә: әйтерсең без
Очар кош балалары.

Күңелләр ярсу дулкындай,
Күренми хәтта яры.
Диңгезгә җитми тынмабыз,
Без — Идел балалары.

Җирдә туып үссәк тә без,
Хыяллар гел югары.
Алсу битләр — ал кояштай,
Без — кояш балалары.

Разил Вәлиев.

КЫШКЫ УРМАН.

Ап-ак, вак-вак сәйлән төсле
Карлар ява.
Наратларның очларында
Энҗе яна.

Урман әкияттәй сихри
Карга чумган.
Агачларны иркәләүче
Нурлар тулган.

Килгән кош та, җәннәт диеп,
Монда очып.
Кышкы урман сәлам бирде,
Мине кочып.

Рәзинә Мөхияр.

ПЕЧӘН ӨСТЕ.

Бер болынны берүзе
Чапты әти, ай, көчле!
Әти чапкан ул печән
Бер кибән булыр тиздән.
Җырлап торган чалгысы
Тип-тигез итеп тезгән.
Мин үзем дә тик тормыйм —
Чапкан печәнне тырмыйм.

Йолдыз.

ЭЧТӘЛЕК

Әсәрдәге могҗиза. 3

Әсәр төзелешен өйрәнәбез. 6

Бала белән Күбәләк. *Габдулла Тукай* 7

Эш. *Габдулла Тукай* 9

Бәрелде. *Шәүкәт Галиев* 10

Тырышып укыйсым килә. *Әхмәт Фәйзи* 10

Курайчы. *(Башкорт халык әкияте.)* 12

Курай. *Әмирхан Еники* 14

Китап докторы. *Хәкимҗан Халиков* 17

Кесә. *Роберт Миңнуллин* 19

Маяк. *Мәрзия Фәйзуллина* 20

Яңгыр. *Мәрзия Фәйзуллина* 20

Җил. *Мәрзия Фәйзуллина* 21

Сабан туе. *Мәхмүт Хөсәен* 21

Пирог эчендә күк бөртеге. *(Әкият.) Джоан Эйкен.*
Америка язучысы. 22

Сүз һәм автор. 29

Чишмә. *Муса Җәлил* 32

Торам менә елмаеп. *Роберт Миңнуллин* 33

Бай сүзләр. 34

Җәен. *Шәүкәт Галиев* 34

Тиеннәр. *Шәүкәт Галиев* 35

Яра. *Роберт Миңнуллин* 35

Тапкыр кыз. *(Әкият.)* 36
Песи. *Роберт Миңнуллин* 39

Охшаш сүзләр. 40
Мактана. *Шәүкәт Галиев* 40
Рифмалы мәкальләр. 41
Рифмалы табышмаклар. 41
Җырдагы рифма. 41

Әсәрне кыскартып сөйләү. 42
Унга кадәр саный белә торган Кәҗә бәрәне турында. *(Әкият.) Алф Прёсн.* Норвегия язучысы. 43
Фил, Учак һәм ак үрдәк турында. *(Әкият.) Дональд Биссет. Англия язучысы.* 48
Кушуч шикәр. *Х. А. Ланглесия. Испания язучысы.* 50
Кыз бала белән Елан *(Австрия халкы әкияте.)* . . . 54
Намус. *(Балкар халык әкияте.)* 58
Урман патшасы. *(Америка индеецлары әкияте.) Луда. Француз язучысы.* 61

Әсәрне өлешләргә бүлү. 67
Ни өчен. *Разил Вәлиев* 68
Тәрбияле малай. *Нур Әхмәдиев* 69
Төлке белән Карга. *(Мәсәл.)* 72
Хикәят. *Каюм Насыйри* 73
Барысын да яратам. *Разил Вәлиев* 73
Бакча. *Рәшит Бәшәр* 74
Сакаллы маэмай. *Илдар Юзеев* 75
Рәсем ясыйм. *Равил Фәйзуллин* 75
Нишләдем мин? *Хәкимҗан Халиков* 76
Уенчыклар остасы мин. *Хәкимҗан Халиков* 77
Чукмар белән Тукмар. *(Әкият.) Абдулла Алиш* . . . 78
Чүлмәк башлы кәҗә. *Бари Рәхмәт* 79

Яхшылыкка — яманлык. *(Әкият.)* 81
Гармун. *Разил Вәлиев* 84
Түтү-тү-тү-түт. *Шәүкәт Галиев* 85

Өлешләр арасындагы бәйләнеш. 88

Каршылык. 89

Мәкальләрдәге каршылык. 90

Табышмаклардагы каршылык. 90

Мәзәкләрдәге каршылык. 91

Иске китап — яңа китап. 91
Аз алма, күп алма. 92
Бар да, юк та. 92
Ничә кош? 92

Мәсәлләрдәге каршылык. 93

Ике ат. *Лев Толстой. Рус язучысы.* 93
Керпе белән Куян. 94

Әкиятләрдәге каршылык. 95

Өч кыз. *(Әкият.).* 95
Карбыз төшләре. *(Үзбәк халык әкияте.)* 97
Чүпкә — алма. *(Болгар халык әкияте.)* 100
Гөлчәчәк. *(Әкият.)* 102

Әсәрләрдәге каршылык. 108

Ике төрле Тәүфикъ. *Шәүкәт Галиев* 108
Миләүшә ничек зур булды? *Евгений Пермяктан. Рус язучысы.* 110
Песи баласы һәм буа эчендә утыручы «ул». *Лилиан Муур. Америка язучысы.* 111
Озак уйлаучы малай. *(Хикәя.) Синтия Райлент. Америка язучысы.* 116
Бер тәңкә. *(Эстон халык әкияте.)* 122

Йолдыз улы. *(Әкият.) Оскар Уайльд. Англия язучысы.* 130
Әтинең тутый кошы. *Синтия Райлент. Америка язучысы.* 144
Ишегалдында. *Нур Әхмәдиев* 148
Комлы комсыз. *Шәүкәт Галиев* 151

Ятлау өчен. 152
Туган авыл. *(Өзек.) Габдулла Тукай* 152
Бәбкәләр. *Шәйхи Маннур* 153
Чык бөртеге. *(Өзек.) Сибгат Хәким* 153
Үзе зәңгәр күзле. *Гамил Афзал* 154
Без — кояш балалары. *Разил Вәлиев* 154
Кышкы урман. *Рәзинә Мөхияр* 155
Печән өсте. *Йолдыз* 155

Учебное издание

Яхин Альберт Гатинович

ЛИТЕРАТУРА

Учебник для 2 класса
четырёхлетней начальной татарской школы

В двух частях

Первая часть

Казань. Издательство «Магариф». 2009

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Яхин Альберт Гатинович

ӘДӘБИЯТ

Дүртьеллык башлангыч татар мәктәбенең
2 нче сыйныфы өчен дәреслек

Ике кисәктә

Беренче кисәк

Редакторы *З. М. Гыйниятова*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Компьютерда биткә салучысы *Р. Ф. Мөбарәкҗанова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Э. Ф. Нурмөхәмmәтова*
Корректоры *С. З. Гыймалетдинова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 22.04.2009.
Форматы 70×90 1/16. Офсет кәгазе. «Прагматика» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 11,7+форз. 0,29.
Нәшер-хисап табагы 5,97+форз. 0,79. Тиражы 3400 д. Заказ В-560.

«Мәгариф» нәшрияты. 420059. Казан, Оренбург тракты, 20а.
Тел./факс (843) 277-52-88; 277-52-62.
E-mail: magarif@mail.ru
http: //www.magarif.com

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

ISBN 978-5-7761-1954-5
9 785776 119545